# Түгәрәк уен

ТАТАР ХАЛЫК ИҖАТЫН ЯКТЫРТУЧЫ МӘГЪЛҮМАТИ-ПОПУЛЯР АЛЬМАНАХ

3/ 2024

***Күн мозаикасы — татар халкының борынгыдан килгән кабатланмас сәнгате. Борынгы һәм хәзерге заман осталары тарафыннан күн мозаикасы бизәкләре ясалган эшләнмәләр соклану уята һәм Татарстанның милли-мәдәни гореф-гадәтләрен саклап калуда мөһим роль уйный***







**УЙНАГЫЗ, ГАРМУННАР!**

ИГРАЙ, ГАРМОНЬ!




Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Казанда XXXIX республикакүләм «Уйнагыз, гармуннар!» халык иҗаты фестивале үтте



1985 елдан бирле уздырылып килүче «Уйнагыз, гармуннар!» халык иҗаты фестивале быел да башкалабызның Галиәсгар Камал исемендәге театр каршындагы мәйданга Татарстан Республикасыннан һәм Россия Федерациясенең башка төбәкләреннән гармунчыларны җыйды.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев бәйрәм кунакларын сәламләп:

– Һәрбер килгән коллективка, кешегә зур рәхмәтләремне җиткерәсем килә! Кайвакыт без көн дә әйтелә торган сүзләрнең мәгънәсе турында уйланмыйбыз. Һәрвакыт «бәхетле бул» дибез. Татар халкы бәхетле, чөнки үзенең Татарстаны, Казаны, Актанышы, Чаллысы, Әгерҗесе, Төмәне, Әстерханы бар. Без бөтен җирдә яшибез, шуның белән бәхетлебез. Тарихыбыз, буыннарыбыз, әби-бабай, әти-әнинең татар итеп тәрбияләве белән бәхетлебез, – диде ул һәм бәйрәм кунаклары белән бергә «Туган тел» җырын башкарды.

Фестиваль кунаклары гармунчылар парадында да катнаштылар, Казан үзәге Бауман урамы буйлап үттеләр. Быел гармунчылар парады башында Татарстанның атказанган артисты Фирдүс Тямаев һәм бер төркем артистлар барды. Алар арасында балалары белән Гүзәл һәм Илназ Баһлар, Ландыш һәм Фәрит Таишевлар, Зәйнәб Фәрхетдинова һәм Зөфәр Билалов, Ришат Фазлыйәхмәтов бар иде.



# Эчтәлек

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫНЫҢ ТРАДИЦИОН МӘДӘНИЯТЕ ЯҢАЛЫКЛАРЫ




4 **«Тылсымлы җеп» бәйгесе дәвам итә**

5 **Белоруссия Республикасында «Живая нить традиций» күргәзмәсе эшләде**

6 **Болгарда «Россиянең рухи бердәмлеге – дөньяга юллама» фестивале узды**

8 **«Түгәрәк уен» – татарлар фольклорына багышланган фестиваль**

10 **Татарстан Республикасында Казан (татар) җөе ясау буенча традицион технология буыннан-буынга тапшырыла**


## ЗӘВЫКЛЫЛЫК БЕЗДӘН БАШЛАНА




12 Р. Исмәгыйлева
**Модельер Руслан Габов: «Мин – ирләр киеме остасы»**


## ҺӨНӘРЛЕ УЛМӘС...




20 Х. Баһаветдинова
**Казан арты татар авылларында милли аяк киемнәре җитештерү тарихыннан**



Түгәрәк уен
№3 (53) / 2024


*Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул,*
*моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул.*
*Г. Тукай*


16+ Татар халык иҗатын яктыртучы мәгълүмати-популяр альманах

Гамәлгә куючылар:
Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге

Редколлегия:
Ирада Әюпова
Марсель Бакиров
Тәлгат Галиуллин
Дания Заһидуллина
Марс Тукаев
Фәрит Юсупов

Директор: Алсу Равил кызы Мифтахова
Баш мөхәррир: Рәзинә Әхтәм кызы Исмәгыйлева

Альманахның иҗат төркеме:
Гөлназ Латыйпова
Илнара Гәрәева

Дизайнер һәм биткә салучы:
Диләрә Нәурузова

Альманах 2020 елның 13 ноябрендә элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр даирәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәт идарәсендә (Роскомнадзор) теркәлгән. Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79590. Журнал өч айга бер чыга. Бәясе ирекле.

Кәгазь форматы 60×90 ⅛.
Күләме 8 басма табак.
Басарга кул куелды: 17.09.2024
Чыгу көне: 26.09.2024
Заказ: 86. Тираж: 1000 экз.

Редакция һәм нәшер итүче:

420021, Казан, Тукай ур., 74 а.
Хатлар язар өчен адрес:
420015, Казан, Пушкин ур., 66/33
Телефон: 293-27-99.
E-mail: tugarakuen@mail.ru

«Фолиант» ҖЧҖндә бастырылды.
Казан, Восстание ур., 100, корп. 6130



Кулъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.
Күчереп басканда, «Түгәрәк уен» альманахына сылтама ясау мәҗбүри.


**Тышлыкта:**
Фоторәсем Арчадагы «Казан арты» этнографик музей экспозициясеннән.
Д. Вайман фоторәсеме


© «Түгәрәк уен», 2024

**ӘДӘБИ МИРАС**



26 Л. Мөхәммәтҗанова
**Сүз сәнгатенең тиңсез хәзинәләре**

**МИФОЛОГИК МИРАС**

30 Г. Гыйльманов
**Өй иясе. Абзар иясе**

**ХАЛКЫБЫЗНЫҢ КҮРКӘМ ЙОЛАЛАРЫ**



35 Л. Хәкимова
**«Ындыр табагына беренче ашлык кайту» күренеше**

**БЕЗГӘ ЯЗАЛАР**



38 Г. Хәкимуллина
**«Халык язмышы – шагыйрь язмышы»**

42 Л. Газизова
**«Максат гармунчыларының дәрәҗәсен күтәрү, авылларга кабат гармун моңын кайтару»**

**БЕЗНЕҢ КИТАПХАНӘ**




46 **Җәнлекләр бәхәсе**

**БЕЗ, БЕЗ, БЕЗ ИДЕК...**



48 Р. Степанова
**«Печән базары»**

53 **Көзге яфраклар**
*(җыр)*

54 И. Степанова
**Чуар тавык әкияте**

**ӨЙ КҮРКЕ – АШ**



58 **Азык-төлек әзерләү фәлсәфәсе...**

60 **Кабак боткасы**

**ЯЛ СӘГАТЬЛӘРЕНДӘ**

62 **Бергәләп бизибез!**

# «Тылсымлы җеп» бәйгесе дәвам итә

30 июльдә Бөтендөнья чигү көне билгеләп үтелә. Әлеге бәйрәм 2011 елда Швеция чигүчеләр гильдиясе иницитивасы белән уздырыла башлады. Бу көнне бөтен дөньяның киерге белән эш итүче осталары бәйрәм итә.

Татарстанда кулдан ясалган бизәкле чигү эшләнмәләре җитештерү буенча «Тылсымлы җеп» республика конкурсына нәкъ менә Чигү көнендә старт бирелде. Конкурс 2024 елда Россиядә игълан ителгән Гаилә елына багышланды.

Әлеге конкурсны гамәлгә куючы – Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, оештыручылары – Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге һәм «Татнефть-Мирас» тарихи һәм мәдәни мирасны саклауга булышлык итү үзәге.

Конкурсның максаты: халык сәнгате мәдәниятенә, Татарстан халыкларының матди-рухи мирасының аерылгысыз өлеше булган декоратив-гамәли сәнгать төрләреннән берсе – чигүгә кызыксынуны арттыру.

Конкурска Татарстан халыкларының үзенчәлекле сәнгатен ачып бирүче махсус техникалардан файдаланып, милли чигеш традицияләрендә башкарылган эшләнмәләр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгендә, түбәндәге адрес буенча кабул ителә: **420021, Казан шәһәре, Габдулла Тукай урамы, 74нче А йорт, 15нче кабинет.**

Конкурс 2024 елның 30 июленнән 30 октябренә кадәр дәвам итә. Конкурс эшләре 2024 елның 18 октябрен кертеп кабул ителә.



# Белоруссия Республикасында «Живая нить традиций» күргәзмәсе эшләде






2024 елның 25 июль-25 август көннәрендә Беларусь Республикасының Милли тарих музеенда «Живая нить традиций» күргәзмәсе эшләде. Бу Татарстан Республикасы Милли музее һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенең уртак проекты иде.

Күргәзмә чын мәгънәсендә Татарстанның декоратив-гамәли дөньясы белән таныштырды. Ул татар мәдәнияте атмосферасына үтеп керергә һәм уникаль сәнгать әсәрләре белән хозурланырга мөмкинлек бирде.

Күргәзмәгә Татарстан Республикасы халыкларының мәдәни мирасы, милли киемнәр, күп гасырлар дәвамында яшәп килүче халык сәнгате эшләнмәләре куелган иде. Республикабызның чигү осталары тарафыннан башкарылган «Татарстанның чигелгән картасы» күргәзмәнең төп экспонаты булды.

Күргәзмәдә Идел һәм Урал буеның Татарстан территориясендә яшәүче өч төп этник төркемә күрсәтелде: төркиләр (татарлар, чувашлар), славяннар (руслар), фин-угорлар (удмуртлар, марилар, мордвалар).

Һәр халыкның милли үзенчәлеге көндәлек тормышта һәм традицион кәсепләрдә чагыла. XIX-XX гасыр азакларындагы фоторәсемнәр киемнәрнең күптөрлелеге, халык кәсебе эшләнмәләрен җитештерү процессы һәм технологиясе белән танышырга мөмкинлек бирә. Халыкларның милли киемнәре музей фондларында саклanучы предметлар нигезендә кабат торгызыла. Сәнгать эшләнмәләрендә кызыл һәм яшел төсләргә җепләрнең өстенлек итүе очраклы түгел. Һәр ике республика флагларында нәкъ менә шул төсләр бар, алар Беларусь һәм Татарстан арасындагы элемтәне символлаштыра.





БЕРДӘМЛЕК
Россиянең рухи бердәмлеге - дөньяга юллама
ЕДИНСТВО
Духовное единство России - послание миру

# Болгарда «Россиянең рухи бердәмлеге – дөньяга юллама» фестивале узды

«Россиянең рухи бердәмлеге – дөньяга юллама» уникаль фестивале ике мәйданчыкка бүленеп уздырылды. Аларның берсе 2024 елның 26-28 июлендә Зөя утрау-шәһәрчегендә XVI-XXI гасырлардагы рус мәдәниятенә багышлап үткәрелде.

Фестиваль кунаклары рус мәдәниятенең төрле аспектлары – дини һәм фольклор музыка, рәсем сәнгате, архитектура һәм төрле һөнәрләр белән таныштылар. Фестиваль көннәренең һәркайсы аерым чорга багышланды, һәм бу анда катнашучыларга һәм тамашачыларга шул заман атмосферасына ныграк якынаерга мөмкинлек бирде. Фестиваль көннәрендә Зөя утрау-шәһәрчегендә 40 000 нән артык кеше булып китте.

16-18 августта фестиваль Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгында дәвам итте. Фестиваль кысаларында Болгарда берничә кызыклы чара уздырылды. Аларның берсе – «Каләм-гарәби галәм» гарәп графикасы каллиграфиясе күргәзмәсе. Ул Болгар цивилизациясе музеенда эшләде һәм гүзәллек сөючеләрне Татарстан Республикасының күренекле осталары Владимир Попов, Нәҗип Нәкъкаш, Ришат Сәлахетдинов, Гөлназ Исмәгыйлева эшләре белән таныштырды. Экспозициядә тугралар, каллиграфик композицияләр, шамаилләр, тәсбихләр бар иде. Күргәзмәдә Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев һәм Татарстан Республикасының мәдәният министры Ирада Әюпова да булды.

Фестиваль кысаларында «Ага Базар» VI Этномәдәни фестивале уздырылды. Ул үзенең мәйданчыгында халык мәдәнияртен популярлаштыручы иҗат коллективларын, аерым башкаручылар һәм музыка уен кораларында уйнаучыларны берләштерде. Ә стильләштерелгән





«Россиянең рухи бердәмлеге – дөньяга юллама» фестивале ачылышында аның почетлы кунагы, фестивальне идея ягыннан рухландыручы, Татарстан Дәүләт Киңәшчесе, Татарстанның беренче президенты ***Минтимер Шәймиев:***

***– Безнең фестиваль дөньяга – дәүләт башлыкларына һәм аларның халыкларына хәзерге чынбарлык шартларында бөтен кешелек өчен уртак булган рухи кыйммәтләргә игътибар юнәлдерүнең, таяну нокталары табу, аларны үстерү һәм ныгытуның гаять мөһимлеге турындагы юллама буларак тәкъдим ителде. Моның ачык мисалы булган фестиваль күп милләтле Россия Федерациясенең рухи бердәмлеген һәм халыклар арасында милләтара татулыкны һәм диннәргә тигез карашны уңышлы тормышка ашыру мөмкинлеген ачык күрсәтте.***







«Ага Базар» урта гасырлар Болгар базары фестивальнең үзәк мәйданчыгына әйләнде, анда Татарстан Республикасы һәм Россия регионнары – Башкортостан, Удмуртия, Чувашия, Мордовия республикалары, Кострома һәм Самара өлкәләренең иң яхшы осталары тарафыннан ясалган уникаль товарлар куелган сәүдә рәтләре тәкъдим ителде.

Фестивальдә әлмәтлеләрнең «Кадим Әлмәт» төркеме чыгыш ясады; ачык һавада тамашачылар яратып өлгергән, заман технологияләре кулланып эшләнгән «Кара пулат» операсы күрсәтелде; балалар өчен 8 серияле «Болгар турында риваять» мультипликацион фильм премьерасы булды.

Шулай ук Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы территориясендә «Милли корал FEST» традицион музыка коралларында уйнаучыларның республика фестивале уздырылды. Фестивальнең эшлекле программасы кысаларында «Этномәдәни мирасны саклау һәм үстерү: традиция, мода һәм дизайн» дигән түгәрәк өстәл дә үткәрелде.

Фестивальдә катнашучылар һәм кунаклар Татарстанның халык артисткасы Миләүшә Таминдарова җитәкчелегендәге Татарстан Республикасы дәүләт камера хоры, Казанның «Зәкәрия» фольклор төркеме һәм Красноярскиның «Otyken» этник төркеме концерты чыгышларын тыңлап хозурландылар.

«Россиянең рухи бердәмлеге – дөньяга юллама» фестивале Татарстан Республикасының гына түгел, бөтен илебезнең мәдәни тормышында чираттагы зур вакыйга булды, ул кунакларга һәм анда катнашучыларга традицион мәдәниятебезнең бай мирасына якынаерга мөмкинлек бирде.



# «Түгәрәк уен» – татарлар фольклорына багышланган фестиваль

2024 елның 28-30 август көннәрендә Татарстанда XVI Бөтенроссия «Түгәрәк уен» татар фольклоры фестиваль-конкурсы узды.





Быел фестивальдә катнашучыларны Татарстан чикләрендә үк каршы алдылар. Һәм алар каршы алучы районнарда концертларда, республиканың иҗат коллективлары күрсәткән мастер-классларда катнаштылар.

Мәсәлән, Ульяновск өлкәсеннән «Урама» татар халык фольклор ансамблен Апас районында каршыладылар.

Мәскәү шәһәреннән «Нур», Киров өлкәсеннән «Кояш» һәм «Идел» татар җыры халык ансамбльләре, Киров өлкәсеннән Сурмятовлар гаилә дуэты, Чиләбе өлкәсеннән «Ләйсән» халык фольклор ансамбле, Төмән өлкәсеннән «Чимги тура» коллективы Балтач районында очрашты.

Мари Эл Республикасыннан «Рәйхан» халык фольклор ансамблен, Чувашия Республикасыннан Ф. Гыйбатдинов исемендәге «мишәр» халык җыр һәм бию ансамблен – Биектау районында көтеп алдылар.

Самара өлкәсеннән «Ак каен» халык фольклор ансамбле – Чистай районында, Башкортстан Республикасыннан «Төмәнәк» татар халык фольклор, «Ак калфак» вокаль





ансамбльләре һәм «Ярмәкәй егетләре» гармунчылар ансамбле Азнакай районында очрашып, чыгыш ясадылар.

29 августта «Түгәрәк уен» татар фольклор бәйрәме Кабан күле яр буенда Россия төбәкләреннән килгән фольклор коллективлар катнашында ачылды. Ул «Хәрәкәттә – бәрәкәт» проекты белән дәвам итте. Биредә алар «Җыен» хореографларыннан һәм музыкантларыннан перформанс, «Капка уены», «Чүпләү», «Биш пар», «Түгәрәк уен» фольклор бию уеннары уйнадылар, күмәк биюләрдә катнаштылар. Бәйрәмне Алсу Мәгъсумҗанова белән Илфак Хафизов алып барды.

30 августта Россия төбәкләреннән килгән «Түгәрәк уен» фестивале коллективлары «Уйнагыз, гармуннар» халык иҗаты республика фестиваль-бәйрәмендә дә катнашты.



**Түгәрәк уен**
Бөтенроссия фольклор фестивале

*«Түгәрәк уен» фестивале – Россиядә татарлар фольклорына багышланган бердәнбер фестиваль. Ул беренче мәртәбә, Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге тарафыннан, 2008 елда Ульяновск өлкәсенең Иске Кулаткы районында уздырыла. Фестиваль татарларның төрле этник төркемнәренең фольклор коллективларын берләштерә, шулай ук татар халкының мәдәни мирасы белән таныштыра.*

*Чара Гаилә елы кысаларында уздырыла һәм «Мәдәният» һәм «Демография» милли проектларының максатларына һәм бурычларына туры килә.*

*Фестиваль Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге тарафыннан уткәрелә.*

# Татарстан Республикасында Казан (татар) җөе ясау буенча традицион технология буыннан-буынга тапшырыла

2024 елның 7–10 сентябрендә Татарстан Республикасында Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни казанышы объекты – «Казан (татар) җөе» турында беренчел исеме «Күн мозаикасы» дип аталган видеофильм төшерелде. Фильм РФ Мәдәният министрлыгының «Россия Федерациясенең матди булмаган этномәдәни казанышы турында медиаконтент төзү» иҗади проекты кысаларында эшләнде. Быел бу проектта Адыгей Республикасы, Дагыстан Республикасы, Ставрополь крае, Ханты-Мансийск автономияле округы, Сахалин өлкәсе, Пермь крае, Липецк өлкәсе, Саха (Якутия) Республикасы, Карелия Республикасы һәм Татарстан Республикасы катнашты.

7 сентябрьдә фильм төшерү төркеме Татарстанның традицион татар җөе белән шөгыльләнү урыны булган Арча районына чыгып китте. Эш Арча шәһәре территориясендә – «Казан арты» этнографик музей экспозициясендә алып барылды.

8 сентябрьдә фильм Биектау районының Ямаширмә авылында урнашкан Халык һөнәрләре һәм гамәли сәнгать остаханәсе музеенда һәм Айгөл Сәләхованың Казан бренды остаханәсендә төшерелде.

9 сентябрьдә фильм төшерү эше шулай ук Биектау районының традицион татар җөе белән шөгыльләнү урыны булган Дөбъяз авылында, «Сәхтиян» ҖЧҖ остаханәсендә дәвам итте. Әлеге предприятие оешуга быел 30 ел була. Шул вакыт дәвамында ул татар милли аяк киеме җитештерүдә алдынгы урында саналып килә. Казан күненнән ясалган бизәкле эшләнмәләр белән директор Әлфия Наил кызы Артемьева һәм аның кече улы Рөстәм Гайнетдинов (ул гаилә бизнесында – өченче буын вәкиле) таныштырды. Предприятиенең чигүчеләре үзләренең бөтен осталыкларын һәм Казан (татар) җөенең төрләрен күрсәттеләр.

Фильм төшерү төркеме Н. Фешин исемендәге Казан сәнгать училищесында да булды. Бирелә 2000 елдан «Декоратив-гамәли сәнгать» белгечлеге укытыла һәм «Күн һәм мехны сәнгати эшкәртү» юнәлеше буенча хәзерлек тормышка ашырыла.

10 сентябрьдә фильм төшерү төркеме Татарстанның Милли музеенда булды, бирелә XIX гасыр уртасы – XX гасыр башына караган милли аяк киеменең музей фонды коллекцияләре, итекче эшендә файдаланыла торган аерым предметлар, Казан артында татар җөе







ясау үсеше тарихыннан булган фотоматериаллар өйрәнелде.

Әлеге проект Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының финанс ярдәме белән гамәлгә ашырыла. Аны оештыручылар: буыннарның рухи-әхлакый һәм мәдәни-тарихи дәвамлылыгын тормышка ашыручы «Ватан» үзәге, В.Д. Поленов исемендәге Россия дәүләт халык иҗаты йорты, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге.







Яңалыклардагы фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# *Модельер Руслан Габов: «МИН – ИРЛӘР КИЕМЕ ОСТАСЫ»*

RUSLAN GABOV
(KAZAN)

*Рәзинә ИСМӘГЫЙЛЕВА,*
*«Түгәрәк уен» журналы*
*баш мөхәррире*




***РУСЛАН ГАБОВ*** *– МИЛЛИ-ТАРИХИ ИРЛӘР КИЕМНӘРЕ МОДЕЛЬЕР-КОНСТРУКТОРЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АТКАЗАНГАН МӘДӘНИЯТ ХЕЗМӘТКӘРЕ, ТӨРЛЕ ХАЛЫКАРА КОНКУРСЛАРДА АКТИВ КАТНАШУЧЫ, «АЛТЫН ХӘСИТӘ» ХАЛЫКАРА КОНКУРСЫНЫҢ АВТОРДАШЫ. 30 ЕЛГА ЯКЫН БОРЫНГЫ ТАТАР СЮРТУКЛАРЫН, ФРЕНЧЛАРЫН ИНТЕРПРЕТАЦИЯЛӘП, ХӘЗЕРГЕ ЗАМАН ИРЛӘР КИЕМНӘРЕ КОЛЛЕКЦИЯЛӘРЕ ТУДЫРЫП КИЛӘ.*








***Игътибар итәсездер – соңгы елларда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов утыртма якалы, галстуксыз киелә торган милли костюмга өстенлек бирә. Образы белән безнең Рәис XX гасыр башында яшәгән татар зыялыларын хәтерләтә. Татарстан Рәисе Аппараты башлыгы Әсгать Сәфәров та шундый ук якалы озынайтылган костюм-френч кия.***

– Без үз милләтебезне, динебезне, традицияләребезне, гореф-гадәтләребезне, милли кухнябызны кадерләп сакларга тиешбез. Динебез, ашамлыкларыбыз, җыр-биюләребездән тыш, безнең әле милли киемнәребез дә бар. Ни өчен аларны артистлар гына кияргә тиеш? Болар бит көндәлек киемнәр булган, – диде бу хакта республика Рәисе.

Ир-атларның милли киеме турында, мөгаен, җентекләп модельер-конструктор Руслан Габов сөйли аладыр – ул бу һөнәрдә чирек гасырдан артык иҗат итә. Аның әйтүенчә, ир-атлар милли киемендәге утыртма якалар күп кенә Азия халыклары милли киеменең дә бер өлеше булып тора.





– Бу – Тукай стиле, модерн, татар халкы атрибутикасы. Элеккеге зыялыларыбыз шундый френчтан йөргән. Ә аңа кадәр кәзәкиләр, күтәренке якалы костюмнар кигәннәр. Бу – безнең классика, консервативлык. Һәм без аны һичшиксез нигез итеп алырга тиешбез. Башка халыклар, горурланып, үзләренең милли киемнәреннән йөри. Безнең киемнәргә дә Рәис өстенлек бирә икән, мин моңа бик шат. Без моңа омтылырга һәм милли киемнәребез белән горурланырга тиешбез. Бөек шәхесләребезнең барысы да милли киемнәрдән йөргән. Тамырлары белән алар чапанга барып тоташа. Кыскартылулары исә – вакыт, мода, уңайлылык таләбе. Ә асылы шул ук кала, – дип исәпли белгеч.

Ул шулай ук традицион татар костюмының иң әүвәл еш кына башка илләргә чыга торган шәһәр зыялылары киеме булуына игътибарны юнәлтә.

– Ләкин бу татар киеме Европа сюртугыннан килеп чыккан дигән сүз түгел. Тышкы охшашлык булса да, аны Кытай френчына да тиңләргә кирәкми, чөнки татар костюмының утыртма якалы кәзәкидән килеп чыкканлыгы мәгълүм, – ди модельер.





Ул шулай ук татар костюмының, ислам традицияләренә яраклы рәвештә, хәзерге заманныкына караганда озынрак, ике як якалы булуын, шулай ук уңнан сулга төймәләнүен билгеләп үтә.

Ирләр милли киемен популярлаштыру һәм актуальләштерү юнәлешендә Руслан Габов үзе дә актив эшли. Бу юнәлештә ул аз санлы авторитетлы белгечләрнең берсе.

Руслан Васильевич Габов Үзбәкстанның Ташкент шәһәрендә туып үскән. Татарстанда ул яңа гасыр башыннан – 2000 елдан бирле эшли. Дизайнер иҗатының башлангыч чоры һәм Казанга нинди кыйммәтле белем багажы белән килүе турында да аның үзен тыңлыйк.

– Ташкентта тусам да, әнием ягыннан нәсел тамырларым Татарстанның Азнакай һәм Актаныш районнарына барып тоташа. Балачагымда һәр елны гаиләбез белән әбием белән бабаемның туган якларына кайтып килә идек. Бүгенге һөнәремнең дә башлангычы – әбиемнән. Ул оста тегә иде. 15 яшемдә минем дә үзем өчен тегәргә өйрәнәсе килү теләге туды. Чөнки Ташкентта яшьләр консерватив булса да, бик матур киенәләр. Хатын-кызлар күбрәк милли



киемнәрдән йөри, ирләр классик чалбарлар, күлмәкләр кия. Мин сәнгать әһелләренә, сәясәтчеләргә тегә торган бик яхшы ательега өйрәнчек булып кердем. Көненә 4 сәгать осталардан дәресләр алам, тәҗрибә туплыйм. Мастерым легендар җырчы Фаррух Кәримович Закировка костюм теккәндә мин гел анда идем. Без аның белән шулай танышып киттек. Бервакыт ул миңа: «Синнән яхшы тегүче чыгачак», – диде. Мин хирург булырга хыяллануым турында әйттем. «Хирург ялгышы артында зират торса, бередә ялгышып тукыманы гына бозарга мөмкинсең. Бозылса, яңа тукыма сатып алып, тагын да матуррак итеп тегә аласың», – дип мине үсендерде ул. Бу язмыштыр дип уйладым. Чөнки һәр кешенең юлында саллы фикер әйтүче, юл күрсәтүче кем дә булса очрый. Минем өчен Фаррух Кәримович шундый кеше булды. Без аның белән әле дә аралашып, күрешеп торабыз. Ул да минем язмышым белән кызыксына, – дип уртаклаша яшьлек хыяллары белән Руслан Васильевич.

Руслан Габов хезмәт эшчәнлеген, Израиль менеджмент академиясенең Ташкенттагы модельер-конструктор белгечлеге буенча профессиональ филиалын тәмамлаганнан соң,




**«Алабуга» халык җыр һәм бию ансамбле. Костюмнар дизайнеры – Руслан Габов**

1996 елда башлый – Үзбәкстан Республикасы сәнгать эшлеклеләре өчен концерт һәм театр киемнәре тегү белән уңышлы шөгыльләнә. Бер үк вакытта Үзбәкстанның иң яхшы осталарыннан дәресләр ала.

2000 елда Руслан әфәнде Казанга күчеп килә. 2005-2008 елларда Людмила Волкова, Наилә Кумысникова, Елена Ермолина кебек рәссамнар белән бергә, «Казан» Милли мәдәният үзәгенең «Эдем» студиясендә ирләр киеме тегү буенча әйдәүче оста булып эшли. Ренат Ибраһимов, Салават Фәтхетдинов, Клара Хәйретдинова, Рөстәм Асаев, Кирам Сатиев, Рөстәм Вәлиев, Фәрит Фәйзрахманов, Николай Коновалов, Ринат Харис, Җәвит Шакиров, Филүс Каһиров, Габделфәт Сафин кебек сәнгать әһелләре һәм шулай ук «Казан» бию ансамбле («Сугышчылар», «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», «Распашка», «Мексика», «Уйгырча» һәм башка биюләр) өчен киемнәрне нәкъ менә алар җитештерә.

Руслан Габов 2005 елдан – Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, 2013 елдан «Созвездие-Йолдызлык» Республика фестивале хәрәкәте белән уңышлы хезмәттәшлек итә: катнашучылар өчен концерт киемнәре тегә һәм сәхнә образы, концерт киемнәре һәм милли костюмнар тудыру буенча мастер-класслар үткәрә.

2019 елда аңа үзен туган ягында күренекле дизайнер-модельер итеп күрсәтергә насыйп була – Үзбәкстанның Ташкент шәһәрендә уздырылган Халыкара мода атналыгында Татарстан Республикасын тәкъдим итә. 2020 елдан Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурсы үзәге оештыра торган «Тормыш стиле – Мәдәни код» халык иҗаты һәм декоратив-гамәли сәнгать Этно-Fashion фестивалендә ирләр коллекциясе белән чыгыш ясый. 2020 елдан башлап ул Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе регионнары, чит илләрдәге татар вәкиллекләре өчен милли киемнәр эшләү һәм тегүдә катнаша.

– Әйе, без хезмәттәшләрем белән бик күп тегәбез. Дәүләт хезмәткәрләре, сәнгать әһелләре һәм башкалар өчен классиканы да тегәбез, шулай да төп яраткан шөгылебез – милли кием. Татар халкының борынгы матур киемнәрен яңа-



**«Алабуга» халык җыр һәм бию ансамбле. Костюмнар дизайнеры – Руслан Габов**

дан торгызасы һәм кешеләргә күрсәтәсе килә. Алар чыннан да игътибарга лаек. Татарлар бик эшчән халык булган, яхшы, сыйфатлы тукымаларны файдаланып, модалы һәм матур итеп киенә белгән. Консервативлык һәм тотнаклылык – татар костюмының нигезе. Бу – классика, алтын урталык, без шуңа таянып эшлибез.

Мин – ирләр киеме остасы, ирләр костюмы турында күп сөйли алам. Бу – френч, кәзәки, классик чалбар, жилет, сюртук. Сюртук пиджактан озынрак, тездән өстәрәк яисә түбәнрәк булырга мөмкин. Ә мөселман чапанының озынлыгын күпмедер дәрәҗәдә саклап кала алдык. Намаз вакытында бөтен гәүдә капланган булырга тиеш, бу – шуның өчен. Ә түбәтәй сырган була. Хәзер аны авыр һәм биек итеп ясарга яраталар, сәйләннәр һәм орнаментлар белән бизиләр, мин моны бик үк дөрес түгел дип исәплим. Элек алай булмаган. Һәммә нәрсәне үлчәп һәм нәзакәтле итеп эшләгәннәр. Бизәк төшерелсә дә, ул зәңгәр түбәтәйгә зәңгәр ефәк җеп белән төшерелгән, чак-чак кына беленеп торган. Хәтта анысы да модалы һәм күпмедер дәрәҗәдә артык купшылык булып саналган, – ди Руслан Габов.

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# КАЗАН АРТЫ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНДА *милли аяк киемнәре җитештерү тарихыннан*

(Ямаширмә авылы мисалында)

*Халидә БАҺАВЕТДИНОВА,*
*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институтының Идел буе һәм Урал алды тарихы бүлеге фәнни хезмәткәре*



КАЮЛЫ ЧИТЕКЛӘР, ЧҮӘКЛӘР ҖИТЕШТЕРҮ – XIX-XX ЙӨЗ БАШЫНДА КАЗАН БИСТӘЛӘРЕНДӘ ҺӘМ КАЗАН АРТЫ ТАТАР АВЫЛЛАРЫНДА КИҢ ҮСЕШ АЛГАН КӘСЕПЛӘРНЕҢ БЕРСЕ. ЯМАШИРМӘ АВЫЛЫ ХАЛКЫ БУЫННАН-БУЫНГА ӘЛЕГЕ ҺӨНӘР БЕЛӘН ШӨГЫЛЬЛӘНГӘН ҺӘМ АЯК КИЕМЕ ТЕГҮНЕ ТРАДИЦИОН ГАИЛӘ КӘСЕБЕ БУЛАРАК САКЛАП КАЛГАН.



**«Туран Арт» фонды җитәкчесе Суфия Хәйбрахманова һәм Халидә Баһаветдинова**

Бу хезмәт революциягә кадәр гаҗәеп бер үзенчәлекле кәсеп формасында шәхси йортларда башкарылган. Чималны гадәттә Казан шәһәреннән алдырганнар.

1902 елгы «Казан өязендә иң киң таралган кәсепләр турында статистик белешмә»дә Чыпчык волосте Ямаширмә авылы халкының чигү, читек җөйләре тоташтыру белән 50 хатын-кыз, 50 яшүсмер егет, 150 кыз бала шөгыльләнгәне билгеле.

1913 елны С. Петербург шәһәрендә уздырылган «Икенче Бөтенроссия вак һөнәрчеләр күргәзмәсе»нең Казан губернасы челтәр бәйләү, чигү үрнәкләре, алтын тегү (золотошвейные), трикотаж эшләнмәләре бүлеге күрсәткечендә Казан өязе Чыпчык авылыннан Авдотья Васильевна Старостинаның бәйләнгән челтәр әйберләре, Ямаширмә авылы хатын-кызлары чигү үрнәкләре белән катнашканлыклары ачыкланды. Бибигафифә Гатауллина ефәк белән чигелгән чүәк, Бәдерхәят Әхмәтсафина, Гайшәбикә Вәлиуллина, Бибигайшә Хөснетдинова, Бибисәйдә Шәмсетдинова каты кәгазь белән җөйләгән читек үрнәкләре күрсәткәннәр. Күргәзмә март аеннан май урталарына кадәр эшләгән. Кагыйдә буенча, урын өчен түләү алынмаган, экспонатлар сатылмаса, май ахырына кадәр кире алырга тиеш булганнар.

Күргәзмәдә катнашучы кызлар бу кәсеп белән XX йөз башыннан ук шөгыльләнгәннәр. Бер елда 300 сумлык чимал сарыф ителгән, алынган табыш 50 сум булган. Подрядчы чимал белән тәэмин итеп, эшләнмәләрне бер башкаручыдан икенчесенә тапшыруны оештыруда арадашчы ролен үтәгән. Әзер товар Казанда сатылган. Тора-бара арадашчылар белән эш итү кайвакыт һөнәрчеләргә табыш алу урынына, киресенчә зыян гына китергән. Алга таба, җитештерүчеләр әртилләргә берләшеп эшләүне кулай күргән.

Бу һөнәргә авыл кешеләре каян өйрәнде икән дигән сорау туа. Ямаширмә авылы халкы Казан шәһәрендә яшәүчеләр белән элекке заманнардан ук аралашып яшәгән. Беренчедән, авыл егетләре Казандагы Татар бистәсеннән кыз алганнар, туганлашканнар, кунакка



йөрешкәннәр. 1764 елгы 3нче ревизия материалларында Үтәгән Тилмәшев Кәримә Ишмәт кызына, Ишморза Ишкин Салихә Ишбулды кызына өйләнгәне мәгълүм. Икенчедән, алар шәһәрдәге завод-фабрикаларда эшләгән. 1870 елда, 1227 кеше яшәгән авылда, шуның 321е эшче булган.

Язучы Гомәр Бәшировның «Туган ягым яшел бишек» автобиографик повестендә «Ул елларда Ямаширмә бүтән авылларга караганда бик зур да, баерак та иде. ... Ирләре Казанда эшләп акча таба, кызлары, киленнәре кышларын байларга читек кайыйлар», дип искә ала. Авылга бу һөнәрне бистә кызлары, яисә Казанда ялланып эшләгән крестьяннар алып кайткан дип уйларга җирлек бар.

1790нчы елларда Казанның популяр итекчесе Мостафа Фәйзуллин, Оренбург губернасының Сәет Посадында булганда, үрнәккә дип, ирләр өчен Бохарада тегелгән кәвешле читекләр сатып ала. Казанга кайткач, әлеге үрнәккә нигезләнеп, ирләр һәм хатын-кызлар аяк киемнәре эшли башлый, аңа башкалар да кушыла.

XIX йөзнең беренче яртысында сәүдәгәр-сәнәгатьче Абдуллин һәм Фәйзуллиннарның фабрикалары булса, 1869 елдан 2 гильдия сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Галиев «азиат аяк киеме» тегү һәм сату эшен башлап җибәрә. Әйтик, аның күн эшләнмәләре чит илләрдә – Чикагода һәм Россиянең Түбән Новгород шәһәрләрендә узган күргәзмә-ярминкәләрдә бүләкләр ала, медальләргә лаек була.

XIX йөз ахырында Казанда бу кәсеп белән шөгыльләнүче унлап эре фирма санала. Барлык эшмәкәрләр диярлек татар милләтеннән, араларында берсе генә әрмән була. Сәүдә кибетләре Печән базарында урнаша. Товарлар шулай ук, Түбән Новгород, Минзәлә, Эрбет һәм башка шәһәр ярминкәләрендә сатыла. Биредән алар Себергә, Кавказ аръягына, Төркестанга, аннары Бохарага, Хивага һәм башка җирләргә дә озатыла. XX йөз башында сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Галиев 25 мең сум капиталы булган «М.И. Галиев уллары белән» исемле Сәүдә




йорты төзи. Әтисенең эшен улы Газизҗан дәвам итә. Шәһәр эшмәкәрләре Казан арты авыллары һөнәрчеләре белән элемтәдә торалар.

Революциядән соң Казан шәһәрендә «азиат аяк киемнәре» җитештерү буенча «Азиатское обувное т-во» (1919), «Ичиги» (1919), «Азад» (1924), «Трудовик» (1924), «Берләшкән көч» (1925), «Умид» (1925), «Чуvяк» (1926), «Таткустпромсоюз» (1926), «Азиатская обувь» (1928) һәм башка әртилләр ачыла. Әмма, кирәкле күләмдә чимал белән тәэмин ителмәү сәбәпле, аларның күбесе тиз арада ябылып бетә. Шуңа күрә берләшеп кооперативлар төзергә мәҗбүр булалар. Нәтиҗәдә барлык кәсепчеләрне берләштергән «Таткустпромсоюз» кооперативы барлыкка килә, ул соңрак «Таткожвалпромсоюз» дип үзгәртелә.

1926 елның 29 маенда «Таткустпромсоюз» кооперативы составында Арча кантоны Дәбъяз волосте Битаман авылында (хәзерге Биектау районы) «Алга» әртиле ачыла. Биредә Бикнарат, Әсән, Кодаш, Олы Көек, Кече Рәс авылларыннан 48 кеше эшли. Бу әртил Казан арты читекчеләренең беренче берләшмәсе була.

Казан губернасында инкыйлабка кадәр 1 млн пардан артык «азиат аяк киеме» җитештерелгән. Әмма революция елларында милли күн эшләнмәләр җитештерү күләме күпкә кими. Татсовнарком продукциянең күләмен арттыру юлларын эзләргә мәҗбүр була. Мәсәлән, 1928 елда «Таткустпромсоюз» кооперативы елга 10 мең пар аяк киеме эшләп чыгара. Татсовнаркомга җавап биргән эш кәгазендә «Татарстан Республикасы кантоннарында булган җитештерүчеләрнең мөмкинлекләре шактый зур булуын истә тотып, берләшеп, елга 200 мең пар аяк киеме җитештереп булыр иде», дип белдерәләр.

1928 елның 14 гыйнварында Арча кантоны Тукай волосте Инсә авылында татар халкының бөек шагыйре исемен йөрткән «Тукай» әртиле ачыла. 1941 елда «Тукай» составыннан Колачы авылы пайщиклары аерылып чыгып, «Труд»




Арча муниципаль архивы. 500 ф. 1 тасв. 43 эш

әртиле оештыралар һәм «Кожвалпромсоюз» идарәсенә буйсыналар.

Ямаширмә авылы чигүчеләре «Тукай» әртиленә карыйлар. Бу елларда әле кәсепчеләр үзләренең өйләрендә эшлиләр. Авыр сугыш елларында икмәк җитештерү, фронтны азык-төлек белән тәэмин итү карт-корыга, хатын-кызларга һәм балаларга йөкләнә. «Тукай» әртиле эшчеләре милли аяк киемнәре җитештерү белән берrәттән, солдатлар өчен киез итекләр ямау белән дә шөгыльләнәләр.

Архивта 1945 елның ноябрь аендагы эш хаклары турындагы хисап исемлеге (ведомость) сакланган. Барлыгы 13 хатын-кыз 746 сум 50 тиен акча эшләгән. Аның 144 сум 79 тиене төрле салымнарга тотылган. Чиста керем 601 сум 71 тиен тәшкил иткән. Уртача хезмәт хакы 46 сум 30 тиен булган. Иң югары керем алучылар: Фатыйма Исхакова (223 сум 74 тиен), Кәшифә Галиәхмәтова (67 сум 82 тиен), Бәдерхәят Сафина (59 сум 24 тиен), Гөл... Шәмсетдинова (52 сум 95 тиен), Асия Гәрәева (48 сум 55 тиен); ә аз эш хакларын:



Распоряжение № 4.
По артели Тукай от 1^го^ февраля 1958 г.
Принять на работу в качестве зав цех
Хасанов Ситдыйк с окладом 450 рублей
испытательным сроком 1 месяц
вышивальный цех дер Ямаширма.
основание заявление
Председатель.
Распоряжение № 5.
По артели Тукай от 1 февраля 1958 г.
Принять на работу в качестве уборщик
Закирова Марьям вышивальный цех
дер Ямаширма с 1^го^ февраля 1958 г.
основание: заявление.
Председатель.
Распоряжение № 6

Арча муниципаль архивы. 500 ф. 1 тасв. 120 эш

Фатыйма Исмәгыйлева (8 сум 90 тиен), Миңлегөл Закирова (10 сум 73 тиен) алган. Югарыда санап үтелгәннәрдән тыш, калганнарның ноябрь аенда хезмәт хакы күләме 21 сум 48 тиеннән 27 сум 77 тиенгә кадәр булган.

1958 елда «Тукай» әртиленең Ямаширмә чигү цехы составында 15 кеше исәпләнә. Әртил Бөек Ватан сугышы елларында балалар бакчасы булган йортта урнаша. Чигүчеләрнең барысы да диярлек 7-8 сыйныф белемле, 16-20 яшьлек сугыш чоры балалары. Араларында иң өлкәне Зөләйха Закирова (1931 елгы). Цех җитәкчесе булып, Бөек Ватан сугышында катнашкан Ситдыйк Хәсәнша улы Хәсәнов (1914 елгы) эшли. Ул сугышның беренче көненнән соңгы көненә кадәр сугышкан фронтовик. Өлкән сержант дәрәҗәсендә Көнбатыш фронт артиллерия батальонында санинструктор булып хезмәт итә. 1942 елда «Сугышчан казанышлары өчен», 1944 елда сугыш кырыннан яралы солдатларны, офицерларны һәм Ленинград өлкәсендәге Перевоз авылы янындагы каты сугышта разведчикларны коткарган өчен «Батырлык өчен» медальләре һәм 1944 елда «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә.

Чигү һөнәренә укучы кызларны остазлар өйрәтә. 1958 елның 1 декабреннән 10 көнлек курслар да оештырыла. Үзәк берләшмәдән инструктор Илсөя Мостафина ярдәмгә җибәрелә.

1960 елның 17 октябрендә Ситдыйк Хәсәновны каравылчы итеп күчерәләр. Аның урынына Борһан Мөхетдин улы Мөхетдиновны (1911 елгы) билгелиләр. Борһан Мөхетдинов та Бөек Ватан сугышы ветераны, инвалид (сугышта бер кулын югалткан), 1958 елда «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнә.

Бу елларда цехка өлге ярдәмендә киселгән әзер төсле күннәр үзәктән китерелә. Каюлы күнгә чигү осталары чүәк, башмак, читек йөзен һәм балтырларын каеп чигәләр. Эшләгәндә махсус калып, мүлинә җебе, дуңгыз кылы кулланыла. Әзер товар үзәк әртилгә җибәрелә. Махсус тегүче җөйнең уникаль техникасын кулланып төпләп бетерә. Кулдан тоташтыру ысулы «Казан (татар) җөе» дип атала.

Казан арты авылларындагы әртилләр берничә тапкыр берләштерелә. Биектау һәм Арча районнарында урнашкан цехларны 1960 елның 5 октябреннән «Арча милли аяк киемнәре



Ямаширмә авылы әртиле чигүчеләре. 1965-1968 еллар

фабрикасы» дип үзгәртәләр. «Тукай» әртиле «Мүлмә бүлекчәсе» дип йөртелә башлый. 1961 елда «Тукай» (Мүлмә), «Сигнал» (Суксу), «Фрунзе» (Олы Әтнә) фабрикаларын берләштерү нәтиҗәсендә «Арча милли аяк киеме җитештерү берләшмәсе» (ПОНО) төзелә. Берләшмәнең филиаллары Ямаширмә, Дөбъяз, Әтнә, Мүлмә, Өнсә, Урта Аты, Утар-Аты, Сөрде, Тимерче авылларында була.

1961 елдан Ямаширмә филиалы яңа бинада эшли башлый. Тау башында агачтан төзелгән зур гына агач йортны мин дә хәтерлим әле. 1963 елдан филиалны Халидә Мөбәрәкҗан кызы Әхмәтҗанова җитәкли (1948 елгы). Соңыннан аны Радания Рәис кызы Гәрәфиева (1956 елгы) алыштыра.

1984 елдан Ямаширмә авылындагы участок цехы яңадан икенче бинага күчә. Барлыгы бу участокта 22,8 мең шартлы пар товар җитештерелә. 1988-1989нчы елларда цехка ремонт ясала, ял итү һәм ашау почмагы булдырыла, участок территориясе төзекләндерелә, куаклар, чәчәк клумбалары утыртыла.

Бер гасырлык тарихы булган каюлы читекләр эшләү һөнәре 1992 елдан түбәтәйләр, калфаклар эшләүгә кайтып кала. Бүгенге көндә һөнәрчеләр ЖЧЖ «Туран Арт» фонды белән хезмәттәшлек итәләр.

**Автордан:**

2024 елның май аенда Биектау районы Ямаширмә авылында Президентның Мәдәни инициативалар фонды гранты ярдәме һәм ЖЧЖ «Туран Арт» фонды җитәкчесе Суфия Камай кызы Хәйбрахманова тырышлыгы белән татар һөнәрчеләренең милли кул эшләнмәләре остаханә-музее ачылды. Музейның концепциясен Ш. Мәрҗани институты хезмәткәре, сәнгать фәннәре докторы Гүзәл Фуад кызы Вәлиева-Сөләйманова төзеде.

Музейда татар халкының милли киемнәре: камзуллар, читекләр, түбәтәйләр, калфаклар; зәркәннән эшләнгән бизәнү әйберләре; эш кораллары, чимал үрнәкләре; Сабантуй келәме һәм башка экспонатлар урнаштырылган.

1970нче елларда «Арча милли аяк киемнәре» җитештерү берләшмәсендә эшләнгән әнием – Әминә Хәбибулла кызы Сафиуллинаның (1918-1999) каюлы читеге дә музейда үз урынын тапты. Әниемә аны мәктәпне тәмамлап, артельдә эшләгән бертуган апам – Дания Зиннәт кызы (1949-2021) 1968нче елларда бүләк иткән иде.



Фоторәсемнәр авторның шәхси архивыннан

# *Сүз сәнгатенең* тиңсез хәзинәләре

*Лилия МӨХӘММӘТҖАНОВА,*
*филология фәннәре докторы, доцент,*
*Татарстан Фәннәр академиясе Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының баш фәнни хезмәткәре*



**Татар халык иҗаты әсәрләре күп кенә мәдәни һәм тарихи үзенчәлекләргә ия. Гасырлар дәвамында яңа фольклор формалары барлыкка килә барган, халык авыз иҗаты жанрларының башка заманныкыннан аерылып тора торган системасы формалашкан. Әсәрләрдә халыкның тарихи үткәне генә түгел, ә аның эчке дөньясы, рухи кичерешләре дә алгы планга чыккан, болар барысы да фольклорның иң үтемле жанрларында гәүдәләнеш тапкан. Татар халык иҗатында мәкальләр, әйтемнәр, канатлы сүзләр (әйтелмәләр), алкышлар (изге теләкләр), әзер җаваплар, җор сүзләр, табышмаклар кебек вак жанрлар үзләренең тышкы төзелешләре белән бер-берсенә шактый якын торалар. Әмма боларның һәркайсының, табигый ки, функция, эчтәлек, форма ягыннан үзенә генә хас булган сыйфат һәм билгеләре дә бар.**

## МӘКАЛЬ НӘРСӘ ДӘ, ӘЙТЕМ НӘРСӘ?

Мәкаль белән әйтем фәндә тиешле дәрәҗәдә өйрәнелмәгән дип әйтеп булмаса да, мәкаль нәрсә дә, әйтем нәрсә, аларны ничек аерырга дигән сорау әле бүген дә еш яңгырый. Бер-берсенә якын борынгы жанрлар булганга, мәкаль белән әйтемне фольклор фәнендә һәрвакыт бергә өйрәнү күзәтелә.

Мәкальләрнең структурасы үзенчәлекле һәм күпкырлы. Бер фикердән яисә тәмамланган бер җөмләдән генә торган мәкальләр була. Бу очракта мәкальдә бер субъект (мәкальдә сүз бара торган кем яисә нәрсә турында фикер), бер предикат (субъектка карата чыгарылган сыйфатлар) була. Мәсәлән, «Сүз күрке – мәкаль», «Беренче коймак төерле була», «Алма агачыннан ерак төшми» һәм башкалар. Монда субъектны һәм предикатны табу кыен түгел, субъект – җөмләдә ия булып килгән сүз, ә предикат исә хәбәр ролен башкара.

Мәкальләр композициясенең икенче төрендә гомумиләштерелгән ике күренеш һәм вәзгыять бергә килә. Мондый төр мәкальләрдәге әлеге объектлар я бер-берсен көчәйтә, я

капма-каршы пардан гыйбарәт була. Мондый структурага ия мәкальләр хөкем чыгара торган үзара бәйләнешле ике җөмләдән тора. «Ир баш, хатын – муен», «Ил тераге – ир, ир тераге – хатын», «Йокы – симертә, акча – тилертә», «Эт чаба дип, бет чаба» һәм башка мәкальләрне моңа мисал итеп китерергә мөмкин. Мондый катлаулы структуралы мәкальләр берничә хөкем-җөмлә эчендә ике күренеш-объектның үзара төрле мөнәсәбәтләрен чагылдыралар. Катлаулы структурага ия мондый төр мәкальләрне бер генә хөкем-җөмлә эчендә ике күренеш-объектның үзара мөнәсәбәтләрен ачыклый торган мәкальләрдән аерып карарга кирәк. Әйтик, «Чиләгенә күрә капкачы», «Чебен дулап тәрәзә вата алмый», «Кара эшкә – ак көмеш». Әлеге мисалларда да ике объектның үзара бәйләнешен тотып алу авыр түгел. Мәкальләр арасында субъектның сыйфатлары гына күрсәтелгән «Таяк ике башлы була», «Ялагайның күзе – көзгә, теле – тасма» кебек мисаллар да җитәрлек.

Төрле структуралы булуына карамастан, мәкальләрне һәрвакыт ике объекттан гыйбарәт булулары берләштерә, шушы сыйфат – мәкальләрне әйтемнәрдән аерып тора торган төп билге.

Әйтем – татар халкына хас афористик иҗатның мөстәкыйль һәм үзенчәлекле төре. Татар халык иҗатының афористик төрләре арасында әйтемнәр, һичшиксез, әһәмиятле урын алып тора. Мәкальләр кебек үк, әйтемнәр дә – борынгы чорлардан бирле халкыбыз яңәшәсендә үскән, татар тормыш-яшәешенең һәр мизгелендә очрый торган гүзәл ядкәрләр. Югарыда әйтелгәнчә, әйтемнәрне мәкальләр белән бергә карыйлар. Моның җитди сәбәпләре дә бар. Әйтемнәр үзләренең кайбер сыйфатлары белән мәкаль жанрына бик якын торалар. Мәкаль кебек үк, әйтемнәргә дә текстның тотрыклы булуы хас, алар да сөйләмне сәнгатьчә бизәү өчен файдаланыла, аның эмоциональ көчен арттыра һәм башкалар. Әйтемнәрне мәкальләрдән аеру гаять мөһим. Мәкальләрдә булган дидактик гомумиләштерү, хөкем-нәтиҗә чыгару әйтемдә булмый. Н. Исәнбәт бу хакта болай ди: «Мәкаль булса, иң элек, ул гомуми бер хөкем, уртак төшенчә була, әйтем булса, ул хосусый бер нәрсәнең билгеле бер ягын әйтү генә була»[1].

Мәкальләр белән чагыштырганда, әйтемнәрнең формасы, күләме, иҗтимагый функцияләре гадирәк. «Ай күрде, кояш алды», «Алтын эчендә йөзү», «Ай җәймәле көн туу» һәм башка әйтемнәр барысы да диярлек бер һәм кыска җөмләдән тора. Яисә җөмләнең бер өлешен генә тәшкил итәләр: «Ничә җәйләр, ничә кышлар», «Кызыл кар яуганда», «Шома боздан шуу», «Арпа эчендә бер бодай», «Абага чәчәк атканда» һәм башкалар. Һәрвакыт субъект һәм предикаттан тора торган ябык структуралы, тәмамланган хөкем-фикергә ия мәкальләрдән аермалы буларак, әйтемнәр – ачык структуралы берәмлекләр, аларда фикер тәмамланмаган була. «Инәдән дөя ясау», «Ике куян койрыгын тоту», «Бет кебек кадалу», «Тумас борын картаю» – әлеге мисаллар аша әйтемнәргә хас структураны җиңел күзалларга мөмкин.



Кыюларга тау да буйсына

Әйтемнәр эчтәлеге һәм мәгънәсе ягыннан да мәкальләрдән шактый үзгә. Әйтем ул – объектка, күренеш, гамәлгә яисә хәлгә хас булган бер генә сыйфатны чагылдыра торган, күбесенчә читләтеп әйтү формасындагы сурәтле сүзтезмә. «Тышы мут, эче ут», «Көймәсе комга терәлгән», «Агылый белән тагылый», «Утлы табага басыру», «Болганчык суда балык тоту», «Элеп алып, селкеп салу», «Чүлмәкчедән кырмәкче» – күргәнебезчә, әйтемнәрнең һәркайсына ритмик бөтенлек һәм гармоник яңгыраш хас. Әйтем текстында субъект үзе булмый, әмма сөйләм контекстында әйтем теге яки бу субъект белән һәрвакыт бәйләнешкә керә. Шушы сыйфаты әйтемне

[1] Исәнбәт Н. Мәкальләребез турында // Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., Т. 1. – 1959. – Б. 212.

мәкальләргә бик нык якынайта да. «Кеше кулы белән утлы күмер тота», «Шатлыктан башы күккә тиде» дигән әйтемнәрне кулланып сөйләшкәндә, боларның субъекты теләсә кем була алганлыгы аңлашыла.

Мәкаль белән әйтем – үзара бик тирән керешкән жанрлар. Мәкальләр гомумиләштерелгән фәлсәфи-дидактик хөкем чыгарса, әйтем аерым бер сүз-фикерне көчәйтеп, куәтләндереп җибәрә дип нәтиҗә ясарга мөмкин. Мәкальләр һәрвакыт тәмамланган фикер-хөкем белдерә торган йомык структура (тулы җөмлә) хасил итәләр һәм бер яки ике ситуациягә мөнәсәбәттә гәүдәләнә торган субъект (логик ия) һәм предикаттан (логик хәбәр) торалар. Ә әйтемнәр һәрвакыт фикер-хөкемнең бер өлешен генә тәшкил итәләр һәм ачык структуралы берәмлек буларак характерланалар; аларда фикер дә, димәк, җөмлә дә тәмамланмаган була.

## КАНАТЛЫ СҮЗЛӘР

Канатлы сүзләр – мәкальләргә дә, әйтемнәргә дә, һәм бигрәк тә афоризмнарга да якын тора торган жанр. Халык иҗаты жанрларыннан аермалы буларак, афоризмның авторы һәрвакыт билгеле була. Афоризм – билгеле автор, галим, язучы, дәүләт эшлеклесе, философ, чичән тарафыннан кыска, соң дәрәҗәдә камил җөмлә белән әйтелгән, тирән фикергә, көтелмәгән эчтәлеккә ия сүзләр тезмәсе, зур булмаган өземтә, образлы тәгъбир. Афоризм – үзе дәлил, үзе аргумент. Мисаллар: «Һәркем үзе аңлардайны гына ишетә» (И. Гете), «Акрынлап ашыгу» (Октавиан Август) һәм башкалар. Х. Мәхмүтов татарча афоризмны «канатлы сүз» дигән термин белән атый, татар шагыйрьләре иҗатыннан аларга күпләгән мисаллар китерә. Мәсәлән, Йосыф Баласагунидан: «Җофарны яшерсәң, исеннән беленер», С. Сараидан: «Җимеше күп агачка таш аталар», М. Акмулладан: «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән», Г. Тукайдан: «Иң мөкатдәс нәрсә – эш», «Эш беткәч уйнарга ярый» һәм башкалар. Татарча канатлы сүзне (әйтелмәне) хикмәтле сүз дип билгеләргә дә мөмкин, асылда ул – эчендә хикмәт яткан, оста итеп әйтелгән, конкрет авторын билгеләп була торган образлы гыйбарә.



Хезмәт төбе – сары алтын

## ТАБЫШМАКЛАР

Тышкы күренешләре һәм кайбер шигъри үзенчәлекләре ягыннан табышмаклар да мәкаль, әйтемнәргә якын торалар. Аларның да күләме зур түгел, еш кына ике, өч, дүрт юллы шигырь формасында төзеләләр. Табышмаклар, мәкаль һәм әйтемнәр кебек үк, татар тарихын ачарга сәләтле. Мәсәлән, «Мич башында – тархан туе» (таракан). Тархан – титул, эчтәлеге белән «эре феодал» мәгънәсенә туры килә. Казан ханлыгында тархан титулы ханга аеруча хезмәт күрсәткән байларга бирелә торган булган. Әйбәт керемле урынга урнашкан түрәләргә карата «Тархан кебек яши!» дигән чагыштырулы гыйбарәнең бүгенге көндә дә кулланылышта булуы да «тархан» тарихи-лексик берәмлегенә барып тоташа.

«Хан», «солтан», «кол», «карача» (кара кеше, хезмәтче), «би», «бикә» кебек шулай ук Казан ханлыгы чорында ук татарларда актуаль булып, бүгенге көндә тарихи сүзләргә әверелгән лексика кулланылган афористик иҗат та игътибарга лаек. Мәсәлән, «Тамчы тама, җиргә җитми, хан билбавы билгә җитми» (беләзек), «Ул хан нәселе түгел, башына таҗ кигән, үзе кол да түгел, аягы каеш белән бәйләнгән» (әтәч), «Би, би баласы, бикә солтан – анасы, аның да бар мазасы, йөз мең алтын – бәһасе» (әдрәс камзул), «Әй, озын, кая барасың? Син, карача, нине беләсең?» (төтен), «Урман, урман эчендә Гөлзәбирә солтан, Гөлзәбирә солтанның ишегенә мөһер суккан» (сургычлы хат) һәм башка табышмакларның үз эчендә, туры җавапларыннан тыш, татар тарихына кагылышлы шактый тирән эчке мәгънә саклау ихтималы зур. Менә, мәсәлән, ал-

тын акча турындагы түбәндәге табышмакны шулай ук тарихи чор белән бәйләнмәгән дип әйтеп булмый: «Бәләкәй генә зәр, җиһан җирне гизәр». Зәр – фарсы сүзе, «алтын» дигәнне аңлата. Бу табышмак – Болгар чорында ук татарларда Иран белән сәүдәнең булуына дәлил.

«Озындыр, камыштыр, карыштыр башы; керәдер, чыгадыр, агадыр яше» (камыш каләм) дигән үзенчәлекле табышмакта татарларда уку-укыту эшләре, әдәбият-мәдәниятнең алга киткән булуына ишарә бар. Кара савыты, каләм, язу турында сүз алып барыла торган «Бохарадан килгән пел (кечкенә предмет мәгънәсендә. – Л.М.), уртасында тасма тел, җанлыдан җансыз туар, ул ни булыр – аны бел» табышмагы да шушы ук фикерне раслый. «Типтем, тирәккә мендем, очтым – оҗмахка мендем» (атка һәм тәвәгә атлану) табышмагы исә – татарлар тормыш-көнкүрешендә шөгыльләр белән бәйле барлыкка килгән.

Төрле чыганакларда теркәлеп яисә телдән-телгә күчеп безнең көннәргә килеп җиткән «Аю бабай акыра, балаларын чакыра», «Акыра да бакыра, тирә-юньне чакыра, утыра зоба кебек, башы яшел суган кебек, кычкыра шайтан кебек», «Урман аша аю караган», «Килдем-киттем, килдем-киттем, бер тиен акча бирми киттем, җәһәннәм!» кебек табышмакларда исә чиркәү образы һәм чиркәүгә чакырып кагылган чаң авазы чагылыш тапкан. Татар халык иҗатының афористик жанрына карый торган мондый ядкәрләр эзоп телле әсәрләр дип аталырга хаклы. Ислам мәдәниятенә ия татарлар өчен чиркәү чаңының матур аһәң булып яңгырамавы яисә аның полпның сөйкемле күренмәве табигый, шуңа да татар фольклорында болар тәнкыйди тискәре тасвирга ия. Шул ук вакытта «Нәдер улмачы: ике йөз егерме тырнагы, егерме аяк өстендә тормагы, унбер башы, унбер тәне, ун җаны, ни гаҗәп, унбер барып, ун кайтмагы» (ун кешенең каберГә җеназа илтүе) кебек табышмаклар татарларның мөселман мәдәниятендә яшәгән халык булуын искәртә. Мәет озатуның ислам тәртипләренә туры килгәнчә тасвирланып, афористик иҗатка үтеп керүе әле Идел буе Болгары чорларыннан ук татарларда исламның өстенлекле урын биләвенә ишарә итә.




## ЙОМГАК

Халык сүз сәнгатенең генезисы һәм иң борынгы формаларыннан алып бүгенге көнгә килеп җитә алган үрнәкләре мәсьәләсе гомумсәнгатьнең барлыкка килүе һәм эволюциясе белән тыгыз бәйле. Халык авыз иҗатының төрле жанрга караган әсәрләре формалашып, камилләшкән, буыннан-буынга күчә барган, бу процесста халык язмышы, тарихтагы күңелне тетрәндерерлек зур вакыйгалар, яшәү тирәлеге, тарихи үсеш-үзгәрешләр, рухи халәт чагылыш таба барган. Чишмә башы бик борынгы чорларга ук барып тоташу сәбәпле, фольклор әсәрләре үз эчтәлегендә халыкның дөньяны архаик күзаллавын да, дини карашларын да берләштерә. Татарларның кайсы территориядә яшәвенә бәйле җирле үзенчәлекләр белән дә тыгыз үрелеп, бу ядкәрләр милли кодларны саклый торган гармоник бөтенне тәшкил итә.

Бөек Тукай әйткәнчә, «Халык зур ул, көчле ул, дәртле ул, моңлы ул, әдип ул, шагыйрь ул». Элекке дәверләрдән туплана килгән тормыш тәҗрибәсе, зирәк акыл, тапкыр фикерләр, тәрбия алымнары, әхлак нормалары, күңел дөньясының, матурлыкның үзенчәлекле чагылышы, хәерле гамәлләрне аңлау-тоемлау рәвеше, дин, фәлсәфә, тарих, хәтер – болар бар да халык иҗатының мәкаль, әйтем, табышмаклары, канатлы сүзләре кебек вак жанрларында яши торган тиңсез хәзинәләр.

**Рәсемнәр «Татарские пословицы» (Казань: Татар. книж. изд., 1979) китабыннан алынды. Рәссам В. Малякин**

# Өй иясе. Абзар иясе

*Галимҗан ГЫЙЛЬМАНОВ,*
*язучы, әдәбият белгече*



**Өй иясе – кешеләргә иң якын торган түбән рух. Шуңа күрә дә кеше аның белән башка рух-ияләргә караганда ешрак очраша. Өй ияләре хакындагы мифларның күп булуы да шуның белән аңлатыла.**

Өй иясе хакында мифик тарихлар күп булса да, бу мифик персонаж өй хуҗалары белән күзгә-күз очрашырга яратмый. Ул кешеләргә күренми торган, әмма һәрдаим аларга үзенең барлыгын сиздереп торган рухи зат. Бик күренергә тырышмаса да, Өй иясенең сурәте миф-риваятьләрдә шактый ачык чагылып калган. Ул күбрәк аксакал картлар яисә сабый балалар күзенә күренә. Бу сабый-нарасый балаларның күңел чисталыгы, һәр нәрсәгә ихлас, самими, ачык мөнәсәбәте булган һәм рухият кануннары белән яшәргә күнеккән өлкәннәрнең тирә-якны, дөнья-яшәешне үтә дә тоемчан рәвештә кабул итәргә сәләтле булуы белән аңлатыла, күрәсең. Өй иясе яраткан кешесенә генә күренә. Начар, бозык, кешелеклелеген югалткан, ялкау кешеләргә өй иясе бөтенләй дә күренми. Өй иясен һәр кеше үзенчә күрә. Әмма аны күзаллаган һәр кеше бу мифик персонажның берничә уртак кыяфәт-сурәт төсмерләре, сыйфатлары һәм тәртибе хакында сөйли.

Өй иясе, гадәттә, кешегә охшашлырак, әмма кешеләрдән тәбәнәгрәк буйлы карт рәвешендә күзгә күренә. Бөкererәк гәүдәсе һәм җыерчык баскан йөзе шул хакта сөйли. Ул ак чырайлы, зур күзле, җитү чал чәчле, кайчакта сакал-мыегы да бар. Ул күп очракта кеше шикелле киенгән булыр, ак киндер күлмәк-ыштаннан, бик сирәк кенә очлаебрак торган башлык кигән итеп күрәләр. Кайчакта аның өстендә кайчандыр өйдән югалган кием-салымны да танып алалар.

Өй иясе, әлбәттә инде, өйдә яши, күбрәк идән астында гомер сөрә. Көндезләрен шунда гомер сөреп, төнге сәгатьләрдә генә үз биләмәләренә чыгып йөри. Ул – төн рухы. Ләкин аның мич артында, мич башында, хәтта чоланда, чормада яшәгән очраклары да бар. Бу очракта аны еш кына икенче түбән рух – Бичура белән дә буташтыралар. Өй иясе өйнең диварына кереп югалырга да сәләтле. Бер урында, әйтик, өй уртасында яисә почмакта кинәт күренеп, шундук гаиб булырга да мөмкин. Өй иясе юктан гына үзен сиздерми. Аның кеше күзенә күренүендә һәрвакыт ниндидер шаукымлы мәгънә, бу нигез халкы өчен бик мөһим вакыйгага ым-ишарә һәм кисәтү бар.

Өй иясе – каршылыклы рух. Шулай да ул күпчелек очракта уңай персонаж буларак



**Рушан Шәмсетдинов иллюстрациясе**

тасвирлана. Бигрәк тә Казан арты татарларында өйне, нигезне, бу нигездә гомер итүчеләрне яклаучы һәм саклаучы буларак кабул ителә. Күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри фикеренчә, Өй иясе өй хуҗаларына файдалы гамәлләр генә башкара. Ләкин моның өчен бер шарт та бар: өйдә, нигездә тынычлык, иминлек булырга тиеш. Өй иясе белән өй хуҗалары арасында үзара килешү, аңлашу булганда, ике арада татулык, дустанә мөнәсәбәт хөкем сөргәндә генә хуҗалар Өй иясеннән уңган булып исәпләнә.

> Өй иясе – бик тыныч һәм бик җитди рух. Ул юкка-барга шаярмый, тавыш чыгарып, шаулап, кеше куркытып та йөрми. Әгәр инде өй хуҗаларын үз итсә, яратса, ул ничек тә бу нигезгә файда китерергә тырыша, гомумән, хуҗа булырга ярата.

Өй иясе – бик тыныч һәм бик җитди рух. Ул юкка-барга шаярмый, тавыш чыгарып, шаулап, кеше куркытып та йөрми. Әгәр инде өй хуҗаларын үз итсә, яратса, ул ничек тә бу нигезгә файда китерергә тырыша, гомумән, хуҗа булырга ярата. Мәсәлән, ул йон, җитен эрли, елаган баланы тирбәтеп китә, идән себерә, он или, бәла-каза вакытында хуҗаларны уята... Иң мөһиме, ул өйне саклый, төнге рух буларак, таңга кадәр өй эчендә йөреп чыга, еш кына авыр сулап, ухылдап куя... Өй иясенең барлыгын сизгән очракта, аны куркытырга, куарга ярамый, ахыры начар бетәчәк. Чөнки ул өй хуҗаларына караганда үзен ныграк хуҗа итеп тоя. Ул бу нигездә бүген гомер итүчеләргә кадәр дә яшәгән, алардан соң да яшәячәк. Рухи зат буларак, Өй иясенең яше юк. Аның адәми затлардан аермасы шунда: ул башка дөньяви яссылыкларга, Коръән телендә әйтсәк, җеннәр дөньясына да үтеп кереп йөри ала. Бу яклап ул чын мәгънәсендә шаукымлы, сихри зат, шуңа күрә аның белән шаярырга киңәш ителми. Өй иясен шулай итагатьлелек һәм буйсынучанлык белән генә аңларга һәм кабул итәргә мөмкин.

Өй иясенә сабыр һәм итагатьле булган очракта, ул үз ярдәмен меңе белән кайтара. Берәр бәла-каза килсә, янгын чыкса, су басса яисә караклар керсә, Өй иясе шундук ярдәмгә киләчәк, ул тәрәзә өлгесен яисә сәке читен шакып, бер дә булмаса, аяктан яки юрганнан тарткалап уятачак...

Өй иясе хуҗа булырга ярата, дидек. Ул кайчакта артык уңганланып та китә. Еш кына аның савыт-саба юганын ишетәләр. Кайчакта мич артына яисә чоланга кереп, он иләп йөри, имеш. Идәнгә иләнгән он күрсәгез, сөенегез: бу яхшы фал – байлык вәгъдә итүче ым-ишарә. Кәгазь шыгырдавы ишетсәләр (янәсе, Өй иясе акча саный), борынгылар акча керүгә, байлыкка юраганнар.

Тыныч кына чәчен тарап утырган Өй иясе дә – байлыкка, муллыкка. Ә менә шатыр-шотыр баш кашыган Өй иясе – начарлык, бөлгенлек, ярлылык фалы. Шулай ук чабата үреп, кием ямап утырган Өй иясе дә хәерчелеккә юралган. Кайвакыт Өй иясе нечкә, үзәк өзгеч тавыш белән улап җибәрә. Бәлки ул шулай елыйдыр? Бу билге дә өйгә бөлгенлек яисә хәвеф-хәтәр килүен хәбәр итә. Ниндидер авырлыктан кисәтәсе килсә, Өй иясе ишекләрне шап-шоп ябып, әйберләрне урыннарыннан алыштырып, чаршау-пәрдәләрне тарткалап йөри башлый. Бернинди кисәтүсез дә, хуҗаларның игътибарын җәлеп итәргә теләп, ул кайчакта стеналарга, бүрәнә-ниргәләргә шыкылдатып утырырга мөмкин. «Онытмагыз, мин дә бар әле монда», – димәкче, ахры, ул.

Өй иясе үзе шыкылдарга яратса да, өйдә юк-барга тавышланып утыруны өнәми. Стена-диварларга сугуны, артлы урындыкта шак-шок килеп атынып утыруны, буш тәлинкәгә кашык белән суккалауны җене сөйми.

Түбән рухлардан исәпләнсә дә, Өй иясе – чисталыгы-пөхтәлеге белән аерылып тора торган мифик персонаж. Аның белән тату, дус яшисең килсә – чиста тор, пөхтә бул, ялкауланма! Нигез туфрагына пычрак су түгелсә, нәҗес керсә, бу туфракта кемдер тәһарәт алса, бел дә тор: әлеге йортта җәнҗал кубачак, Өй иясе өй хуҗаларына бер минут та тынгылык бирмәячәк. Дивардагы әйберләр үз урыннарыннан кубып төшәчәк, гөл савытларыннан балчык чәчеләчәк, җиһазлар авачак. Иң хәтәре – нигезгә начар авырулар

керәчәк... Өй иясе тынгысызланган йортның нигезендә үләксә булуы да мөмкин. Димәк, шушы араларда гына йорт туфрагында берәр мәче яисә күсе үлгән. Эзләп табып, чыгарып ташларга кирәк. Өй иясе шунда ук тынычланыр.

Шушы чисталык тәгълиматыннан соң, Өй иясе белән бәйле тыюлар, кагыйдәләр хакында да әйтергә кирәктер. Аеруча җеп яисә җитен эрләп утыручы Өй иясе хакында күп хәбәрләр килеп җиткән. Шунысы кызык: Өй иясе үзе бу вакытта күренми. Шомлы күренеш: йон хәрәкәтләнә, эрләнә, ә якында беркем дә юк. Гадәттә, Өй иясе кабада, аның да тәрәш тарагында калган йонны гына эрли. Шунысы мөһим: кем дә кем Өй иясеннән калган йонны (җитенне) эрли, ул шул сәгатьтә үк авырый башлый. Шуңа күрә кабада йон калдырырга кушмаганнар, калдырырга туры килгәндә дә, бөтен каба буенча сузып салырга кирәк.

Шаян-шук өй ияләре хакында да мәгълүматлар сакланган. Кайбер шук Өй иясе хуҗаларының чәчләрен, сакалларын үреп китәргә мөмкин. Өй иясе үргән чәчне яисә сакалны сүтәргә ярамый. Толымнарның үзләреннән үзләре сүтелгәнен көтәргә кирәк. Тагын да хәтәреррәге – Өй иясе үргән толымны кисеп ташлау. Шундук һәлакәткә яисә бәхетсезлеккә юлыгасың.

Өй иясе белән ниндирәк мөгамәләдә булырга соң? Ничек аның белән «аралашырга», аны ничек бәхилләтергә? Бу хакта татар фольклорында, аның мифологик мирасында олы бер кодекс-тәгълимат системасы формалашкан. Аның нигезендә бер төп кагыйдә ята: «Өй иясенең барлыгын, тоеп, белеп яшә, иң мөһиме, аның белән тату яшә, әмма башка илаһи яссылыкта яшәүче бу рухи зат белән бернинди уртак эшең дә булмасын».

Өй иясе белән якыннан аралашуны кешенең тәне дә, җаны да күтәрә алмый. Ул авыруга сабыша. Әйтик, кайчакта Өй иясе өй эчендәге ялгыз кешеләргә исемнәре белән эндәшә. Аңа каршы җавап бирергә ярамый, җавап бирә калсаң, шунда ук авырый башлыйсың...

**«Абзар иясенең йорт хайваннары белән мөнәсәбәте бик кызык. Чын кешеләрчә – аның да яраткан аты йә сыеры, шулай ук яратмаган малы бар, ди. Яраткан атына ул, кеше күрмәгәндә, өстәп печән сала, матур, тигез итеп аның ялын үрә.»**

Тагын бер күзәтү: Өй иясе кара төсне яратмый. Кара төстәге тереклек ияләрен, бигрәк тә кара мәчеләрне җене сөйми, киресенчә, Өй иясе булган йортта ак мәчеләр тыныч, имин, озын гомер яшиләр. Үзләре үк дәва чыганагына әвереләләр.

Хуҗалары белән әйбәт мөнәсәбәттә булган Өй иясе йортны явыз рухлардан, кара шаукымнан, хәтәр авырулардан саклый. Ә аның белән яхшы мөнәсәбәт урнаштыру өчен даими рәвештә сәдака биреп торырга кушканнар. Аны кайбер төбәкләрдә «якшәмбе сәдакасы» дип тә атыйлар, чөнки ул якшәмбе көнне авылның мулласына, изге картларына яисә ятимнәргә бирелә. Бу йоланы үтәмәгәндә йортта иминлек, тынычлык, саулык-сәламәтлек булмаячак, диләр. Еш кына, Өй иясен бәхилләтер өчен, тары ярмасыннан махсус ботка пешереп, өй почмагына яисә нигез туфрагына төшереп куялар.

«Нигез туфрагы» дигән төшенчә Өй иясе тәгълиматында хәлиткеч мәгънәгә ия. Нигез туфрагы – Өй иясенең төп яшәү урыны. Кемдер: «Нигезем әйбәт минем», – дип мактана икән, димәк, ул иң элек Өй иясеннән уңган булып чыга. Яңа өйгә күчкәндә йорт хуҗасы бу рухи затны тулысынча бәхилләтеп китәргә тиеш. Башка чыга торган кеше өйдән икмәк алырга, атасыннан ризалык сорарга, иске өйгә кереп, идән астына төшеп, Өй иясеннән яңа йортта тынычлык, иминлек, байлык, бәхет сорап, нигезнең бер уч туфрагын алырга тиеш. Яңа өйгә җиткәнче, юлда чит-ят кеше очрамаска тиеш. Әгәр инде кемдер очраса, йоланы яңабаштан башларга туры киләчәк.

Чөнки туфрак аша иңдерелгән нигез кодрәте әнә шул очраган кешегә ияреп китәргә мөмкин. Бу йола, гадәттә, төн уртасында башкарыла. Яңа нигезгә алып кайтылган бер уч туфрак, теләк-догалар әйтеп, шул өйнең идән асты туфрагына чәчелә.

Өй иясен яңа йортка күчерү йолалары да бар. Бу гамәл дә күпчелек очракта нигез

туфрагын күчерү юлы белән башкарыла. Кайбер төбәкләрдә, бигрәк тә мишәр авылларында, Өй иясен яңа йортка күчерү бер көн буе барган. Иң элек арбалы атка утыртып, Өй иясен яңа йортка алып киләләр. Шул ук нигез туфрагы, мич кораллары, кисәү агачы һәм икмәк-тоз белән бергә килә Өй иясе. Атны куганда: «Әһә, авырайды, Өй иясе утырды», – дип шатланышалар. Яңа өйдә нигез боткасы пешерелә. Мич агартылган, казан кырып юылган булырга тиеш. Ботканы хуҗабикә пешерә. Аның составында бер стакан сөт, бер стакан су, ярты стакан май, ярты стакан тары ярмасы була. Шулардан «нигез боткасы» пешерелә. Ботканы бутаганда уңга гына бутыйлар. Ботка әзер булгач, хуҗа хатын мич янында торган табагачлар янына бара. Табагачка атлана, кисәүгә таяна да: «Әйдә, кер, Йорт иясе, урының җылы мич башында булыр. Тышта озак тордың, туңгансың, әйдә, чәй эч, ботка аша», – ди. Табагачны, кыскычларны мич авызына сөяп куя, кисәүне мич авызына урнаштыра. Аннары өстәлгә ботканы, чәйне бүлеп куя. Өй иясенә аерым урындык, аш-ризык куела. Аннары төп сүз әйтелә: «Эч, аша, тату торыйк, син безгә тимә, без сиңа тимәбез, балаларыбыз исән-сау булсын, бергә-бергә яшик», – ди. Өй иясеннән калган ботканы малларга чыгарып салырга кирәк, ләкин һич кенә дә мәчегә бирергә ярамый!

Татар мифологиясендә Өй иясе белән янәшә Йорт иясе, Йорт анасы кебек персонажлар да бик популяр булган. Алар шул ук Өй иясе башкарган гамәлләрне башкарганнар, кешеләр белән дә шул ук мөнәсәбәтләрдә булганнар. Алардан аермалы буларак, Себер татарларындагы Өй иясе яисә Йорт иясе генә явыз рухлардан саналган, шул төбәктәге миф-легендалардан күренгәнчә, ул кешеләргә зур зыян салган, күп афәтләр алып килгән.

Өй иясе белән янәшә Абзар иясе дә яши. Казан арты, Башкортстан татарларында, татар-мишәрләрдә еш очрый торган бу түбән рух Себер татарларында Мал иясе, Зәнги (Сәнги) баба, Пәша-ана образ-сурәтендә йөри.

Татарларда Абзар иясе абзар-куралаларга, келәтләргә, гомумән, ихата-ишегалдына хуҗа зат буларак билгеле. Йорттагы мал-туар да аның карамагында.

Ул гадәттә берәр хайван кыяфәтендә күренә. Сирәк кенә сыер булып, сирәк кенә өй хуҗасы кыяфәтендә очраштыргалый. Абзар иясе бик сизгер зат. Ул үзенә якын җибәрми, аны бик ерактан гына күрергә мөмкин, диләр.

Абзар иясенең йорт хайваннары белән мөнәсәбәте бик кызык. Чын кешеләрчә – аның да яраткан аты йә сыеры, шулай ук яратмаган малы бар, ди. Яраткан атына ул, кеше күрмәгәндә, өстәп печән сала, матур, тигез итеп аның ялын үрә. Сөймәгән атка көн юк. Абзар иясе мондый атны төне буе борчып-бимазалап чыга, аны тәмам арытып бетерә, хәлсезләндерә. Хәтта шуңа кадәр барып җитә ки, яратмаган аты алдындагы азыкны яраткан аты алдына китереп куя башлый. Абзар иясе сөймәгән атны тизрәк сатарга кушканнар, югыйсә, ул барыбер ябык, хәлсез, зәгыйфь килеш торачак, тиз үләчәк. Гадәттә, Абзар ияләре кара төстәге малларны яратмыйлар. Күпчелек очракта кара төстәге малларның (ат, сыер, сарык һәм башкалар) үлүе шуның белән аңлатыла, ахры.

Абзар иясенең көенә-җаена килеп торырга кирәк. Ул үргән ат ялларын сүтәргә, кисәргә ярамый. Абзар иясе шунда ук бәла-каза, авыру, үлем белән җавап бирәчәк. Аңа атап догалар уку, сәдакалар бирү дә изге эшләрдән санала.

Абзар эченә куелган ялгашларга тәһарәтләнергә, йомышланырга ярамый, – Абзар иясе шунда ук чир, шеш җибәрәчәк. Аның күңелен күрү өчен ботка пешерергә кушалар. Үлем-китемне, чир-авыруларны Абзар иясе шунда ук куып җибәрәчәк.

Абзар иясенең кешегә ярдәме зур. Мәсәлән, ул сыеры бозаулый башлаган, сарыгы бәрәнләгән кешене күршесе яисә туганы тавышы белән, соң чиктә, тәрәзә шакып булса да, уята, яңа туган малны туңып үлүдән саклап кала. Көтүдән йоклап калган хуҗабикәләрне дә Абзар иясе тәрәзә шакып уятучан икән.

Сыер төнлә бозаулаганда, Абзар иясе хуҗага килеп: «Сыерың бозаулады!» – дип кычкыра, ди. Андый вакытта йорт хуҗасына: «Ярый, чыгып алырмын», – дип әйтергә ярамый, бәлки: «Тоз үлчим», – дип кенә җавап бирергә кирәк. Абзар иясе икенче тапкыр килеп кычкырса: «Икмәк үлчим», – дип әйтергә дә тавыш-тынсыз гына бозауны чыгып алырга кирәк. Юкса Абзар иясе ачуланыр, малларга авыру җибәрер.

# «Ындыр табагына беренче ашлык кайту» күренеше

(АРЧА РАЙОНЫ МӘДӘНИЯТ ЙОРТЫ КАРШЫНДА ЭШЛӘП КИЛҮЧЕ «ХӘЗИНӘ» ФОЛЬКЛОР КОЛЛЕКТИВЫ ҮРНӘГЕНДӘ)

*Ләйлә ХӘКИМОВА,*
*Арча районы Мәдәният йорты сәнгать җитәкчесе*






*(Авыл халкы ындыр табагына ашлык кайтуын көтә.*

*Катнашалар:*
*Гүзәл Нигъмәтҗанова (Арча),*
*Динар Бариев (Арча),*
*Фәнис Тимашев (Арча),*
*Вагиз Әгълиуллин (Кишет),*
*Зөлфия Яббарова (Кишет).*

*Массовка:*
*Фәния Хәнәфиева (Кушлавыч),*
*Альмира Хәнәфиева (Лесхоз),*
*Марсель Шәрапов (Сарай Чокырча).)*

**Динар Бариев:** Эше күп булса да, авылдагы шушы урак өсте күңелемә якын минем, әнисе. Сары гәрәбәдәй бөртекләрне күрү, табыннарыбызга икмәк китереп җиткерү өчен маңгай тирләрен түккән игенчеләр белән аралашу, тезелешеп барган кыр «кораблары»н күзәтү – күңелгә рәхәтлек бирә. Хезмәт – авыл халкын берләштерә.

**Гүзәл Нигъмәтҗанова:** Шулай шул, әтисе. Ындыр табагына беренче ашлык олаулары кайтуны да авылдашлар белән бергәләп көтеп алабыз. Беренче уңышны кумәкләшеп кабул итү – борынгыдан калган матур гадәт.

**Фәнис Тимашев:** Кырдагысы түгел, амбардагысы икмәк, дип юкка гына әйтмәгән борынгылар. Бик тиздән әйләнә-тирәгә ашлык киптерү җайланмаларының гөрелтесе белән бергә икмәк исе дә таралыр...

**Зөлфия Яббарова:** Икмәкне үстергән игенчеләргә рәхмәт, алтын башакларның бөртеген дә югалтмыйча җыеп алырга язсын.

**Авыл халкы:** Амин! Шулай булсын!

*(Вагиз Әгълиуллин ашыга-ашыга килә.)*

**Вагиз Әгълиуллин:** Соңга калдым, дип торам. Мондый зур вакыйганы җыр-моңсыз каршы алып була димени? Исәннәрмесез, авылдашлар! Менә гармунымны да алып килдем.

**Фәния Хәнәфиева:** Бик яхшы булган, бик дөрес эшләгәнсең. Икмәк булса, җыр да була.

**Вагиз Әгълиуллин:** Иң куандырганы шул, авылдашлар, яшьләребез дә икмәк кадерен, хезмәт тәрбиясен белеп үсәләр. Әнә, үзләре дә кайтып киләләр.

*(Бәйрәмгә авыл яшьләре дә килеп кушыла, кулларында ураклар. Авыл халкы белән күрешәләр.*



*Катнашалар: Ләйлә-Әхмәт, Зөлфия-Инсаф, Фәрдия-Дилүс, Лиана-Фирдүс.)*

**Фәнис Тимашев:** Исәнмесез, оланнар!

**Ләйлә:** Исәнлек-саулыкмы? Йә, авылдашлар, сөенче җиткерергә ашыгам. Бүген ындыр табагына беренче ашлык кайта.

**Динар Бариев:** Беләбез, үзебез дә күптәннән көтәбез. Кичә бу хәбәрне Әхмәт бөтен авылга таратты.

**Ләйлә:** *(Әхмәткә карап).* Авызыңда бер сүз тормый синең, ә, Әхмәт. Ни арада сөйләп өлгердең? Сөенче алырмын, яңа ураклы булырмын дигән идем...

**Әхмәт:** Ярый инде, Ләйлә, үпкәләмә. Мондый шатлыкны хәбәрне әйтмичә түзеп була димени?

**Зөлфия:**

Көндез йөрдек кырларда,
Хәзер инде җырларга.
Кемнәр хезмәт батыры,
Аңа җырның матуры!

**Әхмәт:**

Күз төшермә күк йөзенә,
Анда бит үсми икмәк.
Җиргә кара, җирне ярат,
Тик шунда бөтен хикмәт.

**Фәрдия:**

Безнең Фәнис бабаебыз *(Фәнис Тимашевка төртеп күрсәтә),*
Кырда күп йөреп арый.
Аргачтын, алтын бөртекне,
Учына салып карый.

**Дилүс:**

Алтын бөртекне иснәсә,
Арганы шундук бетәр.
Безнең җырны тыңлау белән,
Яшь егет булып китәр.

**Ләйлә:** Егетләр-кызлар, авылдашлар, икмәк кайтып җиткәнче бер җырлап алыйк әле.

**Барысы бергә:** Әйдәгез, әйдә!



Автор фоторәсемнәре

# «Халык язмышы – шагыйрь язмышы»



*«Әкиятләрең*
*белән ачылды телем,*
*Казан арты, әй,*
*Казан арты!»*
*(С. Хәким)*

Әтнә районы Күлле Киме авылында урнашкан Сибгат Хәким музее Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимнең (1911-1986) тормышын һәм иҗатын, шул чорның үзенчәлекләрен, авыл тарихын, күренекле кешеләрен өйрәнү юнәлешендә эш алып бара.

Районыбызда иң беренчеләрдән булып оешкан бу музей 1981 елның 26 декабрендә шагыйрь укыган Күлле Киме мәктәбендә аерым бүлмәдә ачыла. Ачу тантанасына Сибгат Хәким гаиләсе, туганнары, каләмдәш дуслары, артистлар белән кайта һәм истәлекләр дәфтәренә: «Туган җиргә, туган туфракка кайттым, яшьлеккә, балачакка, истәлекләргә... Миңа багышланган бу музей шуларның барысын да искә төшерде. Оештыручыларга зур рәхмәт. Сибгат Хәким. 26.12.1981», – дип язып калдыра. Авылыбызның ул яшәгән урамына да шагыйрь исеме бирелә. 1995 елның 5 декабреннән Татарстанның беренче президенты Указы нигезендә Күлле Киме мәктәбе Сибгат Хәким исемен йөртә.

Бүгенге көндә музей гомуми мәйданы 104,9 кв. м. булган 2 залдан тора. Ул ике катлы мәктәпнең беренче катында урнашкан. 1нче зал – тулысы белән Сибгат Хәкимнең тормышы һәм иҗатына багышлана.

Музейның 2нче залында танылган авылдашларыбыз турында стендлар урнаштырылган. Аларда Татарстанның халык шагыйре Лена Галимҗан кызы Шакирҗанованың (Лена Шагыйрьҗан) тормышы һәм иҗаты; Татарстан Республикасы Рәисе администрациясе җитәкчесе Әсгать Әхмәт улы Сәфәров турында мәгълүматләр тупланган. Музей – авылда һәм районда патриотик белем һәм тәрбия бирү үзәкләренең берсе.

Музей фондында 2536 экспонат бар, биредә шулай ук шагыйрьнең үзе исән чагында ук музейга тапшырган шәхси әйберләре дә урын алган. Экспозиция әдипнең нәсел шәҗәрәсеннән башлана.

*«Безнең буын –*
*озын чылбыр ул,*
*Кырлар буйлап*
*узган юлдыр ул.*
*Озын чылбыр.*
*Бик күп боҗралар.*
*Ул боҗралар –*
*бар да без алар»,* –

дип яза С. Хәким.

Шагыйрь яшәгән чордагы авыл йортының интерьеры, анда бишек, бала арбасы, чыгыр, әнисенең шәхси киемнәре, сандыгы һәм шунда ук XX гасыр башында авылыбыз кешеләре кулланган этнографик предметлар куелган: сугылган кызыл башлы сөлгеләр, намазлыклар, күкрәкчә, үрелгән чемодан, күмер самавырлары, күмер савыты, күмер үтүге һәм башкалар. Авылдагы тормышын, Казан чорын, Бөек Ватан сугышы чоры, дуслары, авылдашлары, туганнары белән төшкән фотолардан төзелгән стендлар аның тормыш юлын яктырта. Залда шагыйрьнең шәхси киемнәре



**Музей ачылганда. С. Хәкимне ипи-тоз белән каршы алу. 1981 елның 26 декабре**

дә куелган. Аның эш кабинеты: өстәле, ике урындыгы, китап шкафы игътибарга лаек. Анда шәхси китапханәсеннән алынган китаплар урнаштырылган.

Музей эшчәнлегенең төп юнәлешләре: С. Хәким иҗатында туган тел һәм туган як, Габдулла Тукай, Муса Җәлил, каләмдәшләре, композитор Сара Садыйкова белән хезмәттәшлеге, әдипнең сугышчан юлы, авыл һәм мәктәп тарихы... Экскурсияләр, мәдәни чаралар – кичәләр, әдәби дәресләр белән бергә, конференцияләрдә катнашу өчен, фәнни һәм эзләнү эшләре дә алып барыла, ә алар, үз чиратында, район газетасы битләрендә яктыртыла. Райондагы өч музей бергәләп, һәр елны аерым проект буенча мәктәпләргә һәм балалар бакчаларына күчмә күргәзмәләр белән йөрибез. 2021 елдан башлап, «Сибгат чишмәсе» исемле республикакүләм шигырь сөйләүчеләр бәйгесе үткәрелә һәм финал өлеше Сибгат Хәким музеенда уза.

Туган як... Шагыйрь өчен ул – илһам чыганагы. Гомеренең соңгы көннәренә кадәр авыл, аның табигате, иген кырлары, хезмәт сөюче гади халкы белән горурланып яшәде. Кайту белән, иген үскән басу-кырларга, киң хәтфә болыннарга, авылны урталай бүлеп агучы инеш һәм аның ике ягы буйлап челтерәп аккан чишмә буйларына чыгып китә, авылдашлары белән очраша, аралаша, аларның фикерләрен тыңлый. «Ерακта син, Киме. Читтә, мари чигендә. Сиңа кайту читен, бик читен. Сиңа бик күпләр килеп җитә алмыйлар... мин кайтам. Ничек булса да кайтам. Мин генәме? Студентлар. Ялга чыккан хезмәткәрләр кайта. Ерактан шахтерлар кайта. Җәяүләп, тракторга утырып. Туган якка бер тапкыр кайтып килмәсәң, ел буе тамагы туймый калган кеше кебек йөрисең. Кайтам, күбрәк июньдә. Табигатьнең ташыган чагында», – дигән юллар 1982 елда язылган публицистик язмаларында урын алган. Туган авыл – аның якын һәм кадерле урыны. «Монда кайтсаң, хисләр таша», – диюе белән ул хаклы. Күлле Киме авылының мәктәпкә илтә торган урамында борынгы карт өянкеләр үсә. С. Хәким, кулын артка куеп, өянкеләр белән «серләшеп», әкрен генә шул урам буйлап үтәргә ярата:

*«Сезгә эндәшми, мин кемгә*
*Эндәшим, өянкеләр?*
*Җитте минем дә сезнең күк,*
*Картайдым, дияр көннәр».*
(С. Хәким. Таныш өянкеләр.)

Тукай темасы – һәр әдип өчен якын. Сибгат Хәким өчен аеруча. «Тукай – һәр буын тарафыннан тигез хөрмәт ителәчәк шагыйрь. Ул сине туган көнеңнән алып гомереңнең ахырына чаклы озата килә. «Сабый вакытта күңелеңә синең «Су анасы» шом сала, төштә «Шүрәле»се кытыклап теңкәгә тия. Иртән инде «Туган тел»ен көйләп юанасың. Юк, укымыйсың, көйлисең».

*«Күрдем гомеремдә бу җирнең*
*Күптәрле шагыйрьләрен.*
*Сиңа табынган шикелле*
*Беркемгә табынмадым».*

С. Хәким иҗатында Тукай темасы – иң изге темаларның берсе ул. Туган җире турында


Чишмә буенда

язганда, шулай ук ул Тукайга мөрәҗәгать итә: «Тукай моңы ерактан тартты», – дип язуы белән ул хаклы. Туган тел темасы да Тукайга булган хис белән кушылып китә:

*«Мәктәбем дә,*
*телем дә ул – Тукай,*
*Тукайдагы кебек тел кайда?*
*Мең елдан соң да синең,*
*илем,*
*Кайтасыңны белем Тукайга».*

С. Хәким өчен татарның бөек әдибе Г. Тукай – остаз да, юл күрсәтүче маяк та, шигърият күгендәге иң якты йолдыз да. Шул илаһи көч аны иҗатка рухландырган.

Сибгат Хәким иҗаты – халыкчан иҗат. Шигырь һәм публицистик язмаларында, мәкаләләрендә халык җырлары,


Сибгат Хәким исемендәге Күлле Киме мәктәбе




**Гөлсинә Хәкимуллина**



**Экскурсиягә килгән укучылар белән**

мәкаль-әйтемнәр, афоризмнар бик урынлы һәм күп кулланыла. Милли телгә нигез салынган данлыклы Казан артында туган, кечкенәдән Тукай китапларын, әкиятләрен укып үскән әдипнең шигырьләрендә дә бар алар. «Әкиятләрең белән ачылды телем, Казан арты, әй, Казан арты!» – дип, тикмәгә генә язмаган ул. Туган авылы Күлле Кимедә бик оста әкият сөйләүчеләр яшәгән. Заманында, балаларны авызына каратып, әкият сөйләүче күршесе Шәйхине, күрше авылдан базарга килүче Әхмәтҗанны әдип аеруча яратып искә ала: «Шул бер кечкенә генә тыкрыкта ничә әкиятче! Шәйхи карт. Озын буйлы, таза, бераз бөкрәеп, сөрлегеп йөри. Йорты су буенда. Шәйхи карт бер әкиятне бүленә-бүленә өчәр көн рәттән сөйли. Су буенда карт таллар, өянкеләр, алар кинәт сергә күмелә. Әкиятченең тавышы сине калын кара урманнарга илтеп ташлый. Якында мари урманнары, мари зираты, кирәмәтләр... Бар да җанлана, бар да терелә. Мин аның тавышына, мәкаменә соклана идем» (С. Хәким. «Халык язмышы – шагыйрь язмышы», 39-40 бит).

Сибгатнең әтисе Хәкимҗан абзый китап ярата торган авыл агае була. Кышкы озын кичләрдә, алар өенә тирә-күршеләр җыелышып, китап укыйлар. Чәршәмбе – Күлле Кимедә, җомга көнне Әтнәдә базарга җыелалар. Әдәби-публицистик мәкаләләрендә ул: «Эштән соң, кичке аштан соң күршеләр безгә җыелалар. Кайсы мич буена сузылып ята. Кайсы ишек төбендә чүгәләп утыра. Без сәкедә. Ишек төбендә коедан кичтән алып кереп куйган бер чиләк су. Өстендә боз, өстендә чүмеч. Әти кычкырып укый. Тыңлыйлар, бәхәсләшәләр, торып чүмеч белән бозлы су эчәләр, тагын урыннарына барып яталар. Төн уртасына чаклы шулай. Әти дә, әни дә, без дә шат. Тыңлап утыручылар өйләренә бәйрәмдәге кебек таралалар. Кечкенә, юка китап ипи белән бер шүрлектә, кадерле урында», – дип яза. Менә шулай әти-әнисенең тырышлыгы белән алар гаиләсендә Тукайга, туган телгә, китапка, халык авыз иҗатына, халыкның үткәненә олы мәхәббәт тәрбияләнә.

Сибгат Хәким иҗатында борынгы җырлы уеннар, йолалар, бәйрәмнәр, җыен-Сабантуйлары да урын алган. «Ачлык ел, авыр ел. Сабан туйлары уздырырлык чама юк иде. Ләкин халык безнең мари чигендәге авылның кечкенә генә базарына җыелды. Әнкәй ул көнне сандыктан иң матур күлмәген алып киде. Базар, базардан бигрәк, бәйрәмгә охшый иде. Анда татарлар, марилар, руслар. Татар хатыннарының чулпылары мари хатыннарының тәңкәләре белән сөйләште – кешеләр шатлыкларын бүлеште, уртак бәйрәм, дуслык бәйрәме». Бу – 1920 елның Сабан туе була.

Күренекле әдип «Дуслык бәйрәме» дигән язмасында милли бәйрәмебез – Сабантуйны тасвирлый: «Сабан туе... Тарихы мең еллык. Болгар чорларыннан ук туктаусыз яшәп килгән традицион милли бәйрәм.

Табигатьнең тулып ташыган аенда – июньдә җыела мәйданга халык. Болыннарда чәчәкләр чуар, яулыклар, күлмәкләр чуар, ал, зәңгәр, сары төсләр бергә кушылып уйный. Бу – хезмәт бәйрәме. Халык үзенең көчен сыный, батырларын мәйданга чыгара» (С. Хәким. «Яшә, борчулы җаным!», 13 бит). Чоры шундый: хезмәт һәм бәйрәм янәшә йөри. Күңел ачулар, очрашулар бары тик тормыш тоткасы булган тырыш хезмәттән соң оештырыла да инде.



Сибгат Хәким музееның 1нче залы



Сибгат Хәким музееның 2нче залы.
Лена Шагыйрьҗанга багышланган стендлар

Татар халкы элек-электән эшкә дә батыр булган, авыр хезмәттән соң күңелле итеп ял да иткән. Сибгат Хәким иҗатында да ул яшәгән чорның күңелле мизгелләре онытылып барганны чын күңелдән сагыну хисләре белән сурәтләнгән. «Эш беткәч, авыл халкы бәйрәмен дә иткән. Болыннарда, су буйларында дәрте ташыган, һәр авыл үзенең яңа көен алып килгән, җырлап күрсәткән. Ул җырлар иртәгесен телдән-телгә күчкән... Әтнә, Мәңгәр, Кырлай тирәләре әүвәл-әүвәлдән халык моңнарына бай як. Монда татар бәйрәмнәренең традицияләре нык сакланган» (С. Хәким. «Яшә, борчулы җаным!», 95 бит).

Музей – үткән белән бүгенгене тоташтыручы күпер. Алай гына да түгел, ул – тәрбия, белем бирү урыны. Музеебызда авыл өлкәннәреннән язып алынган язмалар саклана, аларны бүгенге яшь буын өчен ерак үткәнгә сәяхәт, дип атарга мөмкин. Укытучы Ш. Батршин ясап, музейга бүләк иткән рәсемдә авыл уртасындагы елга аркылы салынган агач күпер сурәтләнгән. Узган гасырның 20-30 елларында шушы күпергә яшьләр кичке уенга җыелган. Уен буласы көнне яшьләрнең берсен дежур итеп билгеләгәннәр, ул күпергә салынган такталарны юып, чистартып куйган. Ә кичке эшләрдән соң яшьләр шушы урынга уенга җыелган. Нинди генә авыр чорлар булса да, алар күңел ачарга җаен һәм вакытын тапканнар. Күлле Киме яшьләренең күбесе, очрашу урыны итеп, чишмә буйларын сайлаган. Суга килгән авылның сылу кызлары белән егетләр күбесенчә шунда танышкан. С. Хәкимнең «Фазыл чишмәсе» дип исемләнгән шигыре шул хакта сөйли. Колхозлар төзелгән елларда актив яшьләр тырышлыгы белән авыл клубында музыкаль кичәләр (җыр, бию, шигырь сөйләү...) узган. 1930 елда булган шундый кичәләрнең берсендә Сибгатулла үзе язган шигырен укый. Кичә тәмамланганнан соң, аның янына таныш булмаган кыз килә. «Сездә талант бар, егет, укуыгызны дәвам итәргә кирәк», – дип киңәш бирә. Бу – Күлле Киме участок больницасында врач булып эшләүче апасы Зәйнәп янына кунакка килгән Һава Кутуева була (Гадел Кутуйның бертуган сеңлесе). Аның ярдәме белән Сибгат Хәкимов Казанга укырга килә. Соңыннан үзенең истәлекләрендә ул Һаваны «канатлы кыз» дип атый, чөнки шушы очрашу аның язмышын мәркәзебез Казан, аның күптәнге хыялы – уку, институт, сәнгать һәм шигърият дөньясы белән бәйли.

Сибгат Хәким иҗатында чын шигъри матурлык тормышның үзеннән, чынбарлыктан алынган. Шигырьләреннән һәм публицистик язмаларыннан күренгәнчә, иҗаты халыкчан, чөнки шагыйрь үзе дә – шушы гади халык вәкиле, шушы халык тормышы белән яши. Аның тарихын да, үзе яшәгән чорын да, кешеләрнең өмет-хыялларын да яхшы белә, җаны-тәне белән аңлый.

*«Бөтенләем белән*
*җирнеке мин,*
*Минем барлык*
*нәсел-нәсәбем –*
*Игенчеләр.*
*Җирдән тертеп чыга*
*Һәрбер җырым,*
*һәрбер әсәрем».*

Әйе, «Халык язмышы – шагыйрь язмышы», дип язуы белән ул хаклы. Сибгат Хәким музеендагы экспонатлар да шул хакта сөйли.

**Гөлсинә ХӘКИМУЛЛИНА,**
**Әтнә, Күлле Киме, Сибгат Хәким музееның әйдәп баручы методисты**

**Фоторәсемнәр Сибгат Хәким музее архивыннан**

# «Максат – авыл гармунчыларының дәрәҗәсен күтәрү, авылларга кабат гармун моңын кайтару»

*Татар халкы элек-электән җырга-моңга бай халык. Көмеш телле татар гармуннары авылның горурлыгы. Ә гармунчының урыны туй мәҗлесендә дә, бәйрәмнәрдә дә һәрчак түрдән. Татар авылларында элек-электән гармунчылар булган. Яшьләрнең аулак өйләре, кичке уеннары җыр-моң, гармун белән үткән. Гармун моңы халкыбызның рухи бердәмлеген ныгыткан, иң авыр чакларда да күңелен күтәргән, шатландырган, юаткан.*

Актанышта да милли моңнарга гашыйк халык яши. 2018 елда районыбызда Бөтенроссия «Актаныш гармуннары» фестивале узды. Берничә көн дәвам иткән фестиваль, чын мәгънәсендә, Актанышны гармун иленә әверелдерде. Ике елга бер тапкыр уздырылырга тиеш булса да, пандемия аркасында чираттагы фестиваль гамәлдән төшеп кала язды. Әмма 2017 елда, райондагы иң оста гармунчыларны җыеп, «Баламишкин» ансамбле оештырып җибәргән Актаныш районы Иске Сәфәр авылы Мәдәният йорты җитәкчесе, күңеленә сандугач оялаган Илдус Һарунов ничек тә авыл гармунчыларын берләштерергә көч тапты. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы, Актаныш муниципаль районы бу инициативаны хуплап алды.

2021 елда «Баламишкин»нар Актаныш районы Сабан туенда «Уйнагыз гармуннар» төбәкара гармунчылар фестивале үткәрде. Аннан соң авыл җирлекләренә барып, җәйге кичләрдә халык белән очраштылар, онытыла башлаган гармун көйләрен яңартып уйнадылар, авыл урамнарында бәйрәм ясап, олысын-кечесен гармунга җырлаттылар, биеттеләр.



**«Баламишкин» халык гармунчылар фольклор ансамбле, Актаныш районы**



Быелның июль аенда да Актаныш районының Иске Сәфәр авылында «Яшәсен гармун, тальян моңнары» төбәкара гармунчылар фестивале узды. Авылның Сабантуй мәйданына Яр Чаллы, Казан шәһәрләреннән, республикабызның Актаныш, Минзәлә, Азнакай, Ютазы, Сарман, Түбән Кама, Тукай, Балтач, күрше Башкортостанның Октябрьск, Чакмагыш, Ярмәкәй районнарыннан, Удмуртиянең Сарапул шәһәреннән гармунчы осталар җыелды.

– Мин быел «Татнефть» оешмасының грант конкурсында лəргә, белергә этәргеч ясавын билгеләп үтте. Оештыручыларга әлеге хезмәтләре өчен рәхмәт белдерде.

Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Ирек Шәрипов фестиваль кунакларын Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары, Бөтендөнья татар конгрессы Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев исеменнән сәламләде.

– Татар дөньясында бүген зур бәйрәм. Татар авылларында туган һәрбер идея, һәрбер

2023 елда да «Баламишкин» ансамбле егетләренең инициативасы, тырышлыгы белән Актаныш районы Чөгәнә авылының Сабантуй мәйданында «Авылларда гармун моңы» төбәкара фестивале узды.

Казанда, Татарстан, Башкортстан районнарында гармун моңнары таратучы «Баламишкин» гармунчылар фольклор ансамбленә 50 яшьтән алып 70 яшькә кадәр булган Зөбәер, Балтач, Түке, Урьяды, Богады, Иске Байсар, Иске Сәфәр, Гәрәй авыллары гармунчылары йөри.

– Гармун уйнарга мин өченче сыйныфта укыганда өйрәндем. Ике дус малай да гармунда уйный белә иделәр инде ул вакытта. Беренче укытучым: «Әйдә әле, син дә уйнап кара!», – дип, гармун дөньясына кертеп җибәрде. Әтием гармун алып бирде, «Кара мунчада уйна, җырлый-җырлый уйна, караңгыда да уйнап кара», – дия иде ул. Шул көннән башлап гармунның кулдан төшкәне юк. Кызым да, улым да гармунда уйный беләләр, – дип гармунына булган мәхәббәте турында сөйли Илдус Һарунов.



җиңеп чыктым, конкурс проектында бүгенге фестиваль дә бар иде. Быелгы фестивальне шушы грант ярдәмендә үткәрәм, – диде гармун бәйрәменә нигез салган Иске Сәфәр Мәдәният йорты директоры Илдус Һарунов.

Фестивальне ачу тантанасында Актаныш районы башкарма комитеты җитәкчесе Рөстәм Ильясов гармунның элек-электән гореф-гадәтләребезне, йолаларыбызны саклаучы уен коралы булуын, ә бүгенге гармунны олылау чарасының туган телебезне, милли моңнарыбызны кадерфикер, һәрбер гамәл безнең өчен бик кадерле. Бүгенге бәйрәм өстән кушылмыйча, шушы авыл кешеләренең идеясе белән үткәрелә. Үзегездән, күңелегездән чыккан чишмәгә тәрле төбәкләрдән килеп кушылдыгыз, күлгә әйләндердегез, алга таба да күлебез кипмәсен, бу башлангыч дәвам итсен, – диде Ирек Шәрипов гармунчы милләттәшләребезгә рәхмәт белдереп.

Ирек әфәнде бер төркем гармунчыларга Бөтендөнья татар конгрессының Рәхмәт хатлары, истәлек бүләкләре тапшырды.



ТР Мәдәният министрлыгы каршындагы Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгендә чыгып килүче «Түгәрәк уен» журналы баш мөхәррире Рәзинә Исмәгыйлева халкыбыз җәүһәрләрен саклаучыларга дип алып килгән Рәхмәт хатлары һәм яңа журналлар да үз ияләрен тапты.

«Яшәсен гармун, тальян моңнары» төбәкара гармунчылар фестивале сәхнәсен актанышлыларның якташлары – Татарстанның халык артисты Азат Тимершәех, Татарстанның атказанган артисты Лилия Муллагалиева үзләренең җырлары белән бизәде.

Фестивальнең иң югары ноктасы, әлбәттә, «Гармун (көй) тартыш» бәйгесе. Биредә гармунчының уйнау осталыгы белән бергә җитезлеге, фикер куәте дә сынала. Соңыннан барлык гармунчылар Сәфәр урамнарын да милли көйләргә төрде. Авыл буйлап милли киемнәрдән гармунчылар парады узды.

– Безнең ансамбль халык иҗатын үстерүдә һәм татар халкының мәдәни кыйммәтләрен, халык уеннарын, традицияләрен саклауда актив эш алып





Чалманараттан ук килгән, Такталачык Мәдәният йортында эшләүче Әфка Мәрдәнов та яшьтән үк кулларында сандугач сайрата.

– Гармунчыларның авылларга гармун моңын кайтару идеясе барыбызда да бар иде. Әмма безне Илдус Һарунов оештырып җибәрде. Авыл халкы гармун моңына сусаган. Элек-электән гармун – халыкның шатлыгын уртаклашучы, авыр вакытта юатучы. Тормышны гармунсыз күз алдына да китереп булмый, әмма тавышы гына сирәк ишетелә.



бара. Без фестивальләр генә оештырып калмыйбыз, мәктәпләрдә дә, Пучыдагы Картлар һәм инвалидлар йортында да чыгышлар ясыйбыз. Районда беренчеләрдән булып, махсус хәрби операциядә хезмәт итүче солдатларыбызга ярдәм итү максатыннан хәйрия концертлары куйдык. Дүртенче ел рәттән Казанда Татарстан Республикасы көнендә төп сәхнәдә чыгыш ясадык. Өч ел дәвамында «Уйнагыз, гармуннар!» республика фестивалендә лауреат булдык. Узган 2023 елда «Халык ансамбле» исеме бирелде. «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау (2020-2025 еллар)» Татарстан Республикасы дәүләт программасын тормышка ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Бөтендөнья татар конгрессы «Баламишкин» халык гармунчылар фольклор ансамбленә костюмнар тектереп бирде, кулдан эшләнгән тальян гармун да бүләк иттеләр, – ди Илдус Һарунов.

Бүгенге көндә «Баламишкин» ансамбле җитәкчесенең бар максаты – авыл гармунчыларының дәрәҗәсен күтәрү, авылларга кабат гармун моңын кайтару.

– Музыка уку йортларында баяннарга игътибар зурдан, тик бабайлар уйнаган гармуннарда, тальяннарда уйнарга өйрәтмиләр. Авыл гармунчыларын күрсәтү, таныту кирәк. Элек бала тугач үткәрелә торган бәби ашлары, туйлар, туган көннәр, юбилейлар, армиягә озату мәҗлесләре гармунсыз, гармунчысыз үтми иде. Ә хәзер авылларда гармунчылар күзгә күренеп кими. Менә шушы хәлне үзгәртәсе килә. Без уздырган фестивальләр дә шуңа хезмәт итәргә тиеш. Гармун – милли телебез, милли моңыбыз, татарча аралашу йолаларын саклаучы да, – дип, күңелендәгесе белән дә уртаклашты Илдус әфәнде.

Без уйнаган көйләрне халкыбыз яратып тыңласын, яшьләр дә кулларына гармун тотсын, өйрәнсеннәр иде. Миңа гармунны ундүрт яшьтә абыем алып бирде. Баштарак уйнарга өйрәнә алмыйча җәфаландым. Соңыннан инде кулымнан да төшермәдем. Гармун – кешенең тормышында күңелен күтәрә торган уен коралы, – ди ул.

**Ләйсән ГАЗИЗОВА,**
**«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы**
**«Актаныш-информ» журналисты**

Автор фоторәсемнәре




**Казах халык әкиятләре / (тәрҗ. Г. Гайнуллина; рәс. А. Кадырбаев; кереш сүз авт. Е. Искаков). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2024. – 56 б.: рәс. б-н.**

# ҖӘНЛЕКЛӘР БӘХӘСЕ

Борынгы заманда җәнлекләр арасында бәхәс туган, имеш. Ай календаре буенча беренче елны кайсы җәнлек исеме белән атарга?

Сыер әйткән, ди:

– Мин кешегә ит-тире, сөт-май бирәм. Беренче ел минем исем белән аталырга тиеш!

– Син биргәнне мин дә бирәм. Өстәвенә кеше миңа атланып йөри, – дип җавап кайтарган ат.

– Син бит көчсез! – дигән, атка каршы төшеп дөя. – Синдәге куәт миндәге куәт белән чагыштырырлыкмыни? Мин күтәргән йөкнең яртысын да тарта алмыйсың бит син. Ашавын шәп ашыйсың анысы. Сиңа солы да печән бир, чишмә суы эчерт. Миңа энәле үлән дә ярый, сусыз да озак яши алам. Минем дә сөтем тәмле, итем дә ашарлык, тирем дә шәп.

Шунда сарык бәрәне, барысын да мөгезе белән төртеп, урта бер җиргә басып тавыш күтәргән, ди:

– Ә минсез казахның тирмәсендә киезе дә булмас иде. Толыбын кем тиресеннән тегә ул? Ә сарык маеннан тәмле ни бар? Шулай булгач, минем исем беренче торырга тиеш.

Барысы да туктап уйга калган, ди. Әмма бәрәнгә эт каршы төшкән:

– Юкны сөйлисең! Менә мин булмасам, сине бүреләр күптән ботарлар иде, сөякләреңне чәйнәп йотарлар иде.

Әй бәхәсләшәләр, ди, болар, әй бәхәсләшәләр, кояш баеп, төн җиткәнен дә сизми калганнар, ди. Тычкан гына берни әйтми икән. Бөтенесе сөйләп туйгач, хәтта дөя белән этәч тә пышылдап кына сөйләшә башлагач, тычкан әкрен генә үз тәкъдимен керткән.

Шулай итеп, яңа елда таң атканын кем беренче күрә, шуның исеме белән ел аталыр, дип сүз куешканнар болар. Әй сөенгәннәр, ди, җәнлекләр. Аеруча дөя шат, ди. Янәсе, иң озын буйлысы ул бит. Көнчыгышка таба борылганнар да таң атканын көтәләр, ди, болар. Тычкан дөя янынарак баскан.



– Син, бахыр, кояшны беренче булып күрергә өметләнмисеңдер бит? – дип көлгән моңардан дөя.


– Иртән күз күрер, – дигән тычкан.

– Мин барыгыздан да озынрак, таң атканын беренче булып мин күрми, кем күрсен! – дип шапырынган дөя.

Таң атуга табарак барысы да көнчыгышка текәлебрәк карап тора башлаган. Берзаман иң беренче булып тычкан аваз салган:

– Кояш! Кояш!

Шунда гына дөя тычканның үзенең өркәче өстендә икәнен аңлап алган. Тычкан дөянең озын йоны буйлап өркәчкә үрмәләгән булып чыга. Дөя ачуыннан тычканны бәреп тә төшерә, таптамакчы була, әмма тычкан, күз ачып йомганчы, көл эченә чумып юк була. Дөя тычкан белән әвәрә килгән арада, һәр җәнлек ел исеме ала. Дөяне исә бу акылсызлыгы өчен ел исеменә ия булудан мәхрүм итәләр. Шуннан бирле дөя көлне күргә шуа башлый, ди. Һаман теге тычканны табып таптарга һәм беренче ел исемен үз исеме белән атарга хыяллана, имеш.



**Рәссам А. Кадырбаев**

**(Әлеге әкият балалар өчен чыккан «Казах халык әкиятләре» китабыннан алынды.)**

# «ПЕЧӘН БАЗАРЫ»

***(Сценарий)***

*Рәйханә СТЕПАНОВА,*
*Кукмара, 7нче «Кыңгырау» балалар*
*бакчасы тәрбиячесе*

**Соңгы елларда халкыбызның гореф-гадәтләренә, йолаларына һәм бәйрәмнәренә игътибар арта башлады. Мин дә үзем хезмәт куйган «Кыңгырау» балалар бакчасында туган төбәгебезнең тарихы, мәдәнияте, теле белән кызыксыну, халкыбызның гасырлар дәвамында буыннан-буынга күчеп килгән гореф-гадәтләрен кире кайтару, үстерү өстендә эшлим.**

**Бүген сезгә бакчабызда узган «Печән базары» бәйрәмен тәкъдим итәм.**






*(Балалар татар көе астында залга керәләр, ярымтүгәрәк ясап басалар. «Хәерле көн» җыры башкарыла.)*

**Әхмәд:**

Шундый зур безнең базар,
Шундый бай безнең базар.
Базар бай, кәсәсе ай-вай.
Күпмегә алсам, шуңа сатам.
Кирәкме, алмыйсызмы?

**Ралинә:**

Карап тормый ара еракка,
Дуслар килә безгә кунакка.
Дуслык – безнең тормыш үзәге,
Дуслык – безнең бәйрәм бизәге.

**Мәликә:**

Килде ярминкә даулап,
Килде ярминкә шаулап,
Бәхет, муллыклар яулап.
Апакайлар, дускайлар!
Эшегезне ташлагыз,
Йон йомарлап ятмагыз,
Орчык шырылдатмагыз,
Ярминкәгә барыгыз.

**Айгөл:**

Без биибез, тыпыр-тыпыр,
Без биибез тып-та тып.
Бер бии башласак, бик тиз генә
Булмый безне туктатып.

*(Татар халык биюе. Биегәндә Сәйдә, Илүзә, Зилә, Влада, Алия – сатучы ролендә, Мәликә, Алия, Раяз җитәкләшеп баралар.)*

**Мәликә:**

Дусларым белән бергә,
Базарга килдем иртән.
«Печән базары» ярминкәсе,
Күңелле була икән.

**Алия:**

Шатлыклар – күңелебездә,
Ай-кояш – күгебездә,
Килегез, дуслар, кунакка,
Ярминкә бүген бездә!
Шундый зур безнең базар,
Шундый бай безнең базар.

**Раяз:**

Әйдәгез, җитезрәк,
Атлагыз тиз-тизрәк!



Иң шәп товар – безнеке,
Безнеке – «Кыңгырау»ныкы.

**Сәйдә:**

Муенсаңның очларына,
Ник такмадың көмешен?
Яхшы товар син сорыйсың,
Бирерсеңме өлешен?

*(Мәкальне дәвам иткән һәр балага муенса бирелә.)*

Кем эшләми – шул ашамый.
Эш беткәч – уйнарга ярый.
Җәй эшләсәң – кыш ашарсың.
Ипи-тоз – якты йөз.

*(«Әйдә, дустым, биергә» җырлы-биюле уен башкарыла.)*

**Тәрбияче:**

Шаулый, шаулый самовар,
Безнең күз алдыбызда.
Ачулана, турсая,
Түшәмгә пар җибәрә.

*(Уртага зур самовар куела. «Самовар» уены уйнала.)*

**Илүзә:**

Ни кирәк, шул бар!
Җаның теләгәнен сайлап ал.
Чүлмәк, чиләк, көянтә –
Дустым, сатып ал, әйдә.

*(«Тирмә» башкорт халык уены уйнала. Илүзә уен өчен балаларга яулыклар өләшә.)*

Без, күңелле балалар,
Җыелдык түгәрәккә.
Йөгерәбез һәм уйныйбыз,
Күңелле ял итәбез.

**Тәрбияче:**

Чиккән чүәк, кулъяулыклар,
Түбәтәйләр, калфаклар.
Чүлмәк, тукмак, курчаклар –
Барысы да бар монда.

**Зилә:**

Итек, читек, энә, без,
Матур итеп чигәбез.
Кирәкмиме, алмыйсызмы,
Әллә киеп карыйсызмы?

*(Керәшен халкының «Чабата» уены уйнала.)*

**Әсгат:**

Чакыручы барында,
Торма капка янында.
Биегәнгә мал җәл түгел,
Биеп кал яшь чагында.

*(Төрле милләт биюләренә попурри башкарыла.)*




**Мәликә:**

Уеннар бит, дусларым,
Витамин кебек алар.
Күңелләрне үстерә,
Йөрәкләргә көч бирә.

*(«Эх, Зилем, Зиләле» җырлы-биюле уен уйнала.)*

Җитәкләшеп, тезелешеп,
Без базарга барабыз.
Базарда, матур аланда,
Җырлап-биеп алабыз.

Эх, Зилем, Зиләле,
Сандугачым кил әле.
Кил әле, дустым, кил әле,
Бергә әйләник әле.

Кояшлы матур аланда,
Гөлләр чәчәк аталар.
Тирә-юньгә ямь, матурлык,
Хуш исләр тараталар.

**Нәзилә:**

Татар халык ашлары,
Барысы да бар бездә.
Гөбәдияләр, чәк-чәкләр,
Тәкъдим итәбез сезгә



*(Кунаклар чәк-чәктән авыз итәләр.)*

*(«Печән базары»на әби килә.)*

**Әби:** Исәнмесез, кадерле балалар, килгән кунаклар! «Кыңгырау» балалар бакчасында «Печән базары» буласын ишеткәч, ашыга-ашыга, йөгерә-йөгерә килдем.

**Тәрбияче:** Исәнме, Асыябикә әби, хуш киләсең, түрдән уз. Әйдә, бераз утырып, ял итеп ал. Балалар, ә без әйдәгез, сезнең белән, ярминкә бәйрәмен дәвам итик.




*(Күмәк бию башкарыла.)*

**Әби:** И-и, балалар, сезгә карап балачагым искә төште. Без дә, әти-әниләргә ияреп, «Печән базары»на бара идек. Андагы биюләр, тәм-томнар, уеннар! Ул бәйрәмдә без бик күңелле ял итә идек. Без аңа берничә көн алдан әзерләнеп, иң матур киемнәребезне киеп килә идек.

Уйнагыз да, җырлагыз да,
Рәхәт чакларыгызда.
Алсу гөлләр чәчәк атсын,
Йөргән юлларыгызда.

**Тәрбияче:**

Асыябикә әби, матур теләкләрең өчен рәхмәт сиңа.

*(Гармун тартып малайлар керә, бергә җырлыйлар.)*

Печән базарына бардык,
Күп нәрсәләр алдык без,
Җырладык та, биедек тә,
Күңелебезне ачтык без.
***Кушымта:***
Эх, алмагачлары,
Сайрый сандугачлары.
Сайрый, сайрый, сайрый,
Сайрый сагындыра башлады.

Насыйп булгач, күрештек без,
«Кыңгырау» бакчасында.
Дус-туганнар булып шулай,
Яшәсәк иде гел дә.

Бәйрәм иттек, эх, дусларым,
Бүген барыбыз бергә.
Килдегез дә карадыгыз,
Рәхмәтләр яусын сезгә.

*(«Туган тел» җыры башкарыла.)*

**Тәрбияче:**

Киштәләрдә товар бетте,
Күктә алтын ай калка.
Күңелле «Печән базары»,
Чөлтәр капкасын яба.

Автор фоторәсемнәре

# КӨЗГЕ ЯФРАКЛАР

Наилә Яхина көе,
Нурзия Мирхазова сүзләре




*Кызгылт-сары яфраклар,*
*Җир өстенә сибелде.*
*Шул матурлыкларны күреп,*
*Көз кызы да сөенде.*

***Кушымта:***
*Тирә-якка, күккә чөеп,*
*Туйганчы бер уйнадым.*
*Бүләккә дип, әниемә*
*Бәйләм итеп җыйнадым.*

*Көз кызының бүләге,*
*Булмәбезне бизәде.*
*Кояшка тиң яфраклары,*
*Озын гомер теләде.*

***Кушымта:***
*Тирә-якка, күккә чөеп,*
*Туйганчы мин уйнадым.*
*Бүләккә дип, әниемә*
*Бәйләм итеп җыйнадым.*



# ЧУАР ТАВЫК ӘКИЯТЕ

***(Сценарий)***

*Ильвира СТЕПАНОВА,*
*Кукмара шәһәре Чыңгыз Айтматов исемендәге Iнче гимназиянең IIнче сыйныф укучысы*

**Тычкан:**
Безнең өйдә бик күңелле,
Ә шулай да ... бер мәлне...
Әгәр инде кызык булса
Утыр, сөйлим бу хәлне.

Гаиләдә әби, бабай,
Песи, мин, чуар тавык.
Тавык беркөн шаккаттырды,
Алтын йомырка салып.

**Тавык:**
Үземнең дә исем китте,
Бу хәлгә хәйран калдым.
Беләсезме, мин бит менә,
Алтын йомырка салдым.

**Тычкан:**
Моның белән бетсә бер хәл,
Әби, бабайны күрсәң...
«Байыйбыз!» дип сөенгәнен,
Бу икәүнең син белсәң...

**Бабай:**
Әйдә, карчык, керик өйгә,
Бер савыт эзләп табыйк.
Бу хикмәтле йомырканы,
Әйдәле, ватып карыйк...

**Әби:**
Бигрәкләр дә затлы инде,
Гади түгел, алтын шул.
Безнең тавык, кытый-мытый,
Йомыркалар салмый ул.







**Тычкан:**

Шаклар каттык песи белән,
Торабыз аптырашып.
Ул да тими, мин дә качмыйм,
Калдык без авыз ачып.

Озак кына күзәттем дә,
Мин ярыктан бу хәлне
Булмас бу, дип, өскә чыктым,
Күргәч, исең китмәле...

Шул чак нәрсә булды дисез,
Төште китте тәгәрәп.
Әби елый, бабай елый,
Мин йөрим әйләнгәләп.

**Песи:**

Дөрес сөйли тычкан дускай,
Шаккатмалы хәл булды.
Үз күзләрем белән күргәч,
Хәтта күңелләр тулды.

Тавык дисәң дә тавык шул,
Алтын йомырка сала.
Тычкан белән икебезгә,
Аны сакларга кала.





Күзәттек без озак кына,
Мәш килде әби, бабай.
Бер алалар, бер куялар,
Шаккаткыч инде, малай...

**Тавык:**
Җәлләдем әби-бабайны,
Еламагыз, мин әйтәм.
Моның хәтле күз яшенә
Хәзер мин агып китәм.

Булыр әле, кайгырмагыз,
Соңгы йомырка булмас.
Алтын елата гына ул,
Аны ашап, тамак туймас.

**Әби-бабай бергә:**
Исән-сау гына була күр,
Гап-гади йомырка сал.
Киңәшләрең дә бик яхшы
Гел дә шундый булып кал.



**Фоторәсемнәрдә «Кыңгырау» балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр.**

Автор фоторәсемнәре

«Татарханә»
проектының «Татар табыны»
рубрикасыннан.
Мастер-классны «Тәмле булсын»
рестораннар челтәре җитәкчесе,
Татар ашлары һәм мәдәнияте
Халыкара ассоциациясе
президенты, Татарстан
Республикасының атказанган
халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсе
хезмәткәре, танылган аш-су остасы
**Резидә Кыям кызы
ХӨСӘЕНОВА**
алып бара

# АЗЫК-ТӨЛЕК ӘЗЕРЛӘҮ ФӘЛСӘФӘСЕ...

«Иршад әл-Әтбиха илә Истихзар әл-Әтгыймә» («Пешекчегә аш-су әзерләү турында юллама») исемле китап мәшһүр мәгърифәтче, педагог һәм энциклопедияче галим Габделкаюм Насыйри кулы белән язылган. Тәмле һәм файдалы ризыкларга багышланган бу китапның темасы авторның никадәр киң колачлы, тирән белемле шәхес булуына бер дәлил булып тора. Гомерен татар халкының тормыш-көнкүрешен җентекләп, этнолог буларак өйрәнүгә багышлаган Габделкаюм әфәнденең башына шушындый китап язу турындагы фикер килмәсә, бәлки сәер булыр иде. Шуңа күрә әлеге китапны гамәли кулланма буларак кына түгел, ә галимнең этнографияне һәм милли культураны өйрәнүенең бер өлеше итеп тә танырга була. Китапның кереш өлеше аерым игътибарга лаек. Биредә автор азык-төлек әзерләү фәлсәфәсе, туклану әдәбе турында сүз йөртә, ашауның кайбер гомумфизиологик үзенчәлекләрен ассызыклый. Китапның төп өлешендә асыл татар милли ризыклары һәм эчемлекләрен әзерләү рецептлары белән бәрабәр башка шәркый-мөселман милләтләренә хас булган тәгамнәр дә бирелә. Автор тәкъдим иткән рецептларның катлаулылыгы һәм аларның гамәлдә кулланылышы төрле дәрәҗәгә ия. Мәсәлән, кайбер ризыклар бәйрәм табынын, төрле тантаналы мәҗлесләрне бизәргә лаеклы булса, кайберләре көндәлек туклану өчен яраклы. Арасында хәтта тиз итеп, вакыт кысынкы булган чакларда табын әзерләргә яраклы ризыклар җитештерү тасвирламалары да бар. Автор тәкъдим иткән рецептларга кертелгән азык-төлек төрләрен игътибар белән күздән кичергәндә татар милли









кухнясының никадәр төрле һәм бай булуы турында нәтиҗә ясау кыен түгел. Тасвирланган ризыклардан милли кухняның борынгы гореф-гадәтләренең чагылышы булуы белән беррәттән, аның башка халыкларның аш-су культурасы һәм казанышлары өчен ачык, «кунакчыл» булуын да күрергә була. Рецептлар арасында фарсы, үзбәк, төрек, гарәп, кавказ халыклары кухняларына хас булганнары да аз түгел. Шулай ук урыс һәм украин кухняларыннан да алынган ризыклар бар. Биредә сүз безгә таныш булган борщ белән щи турында гына бармый. Мәсәлән, «урысча пылау» рецепты гына да ни тора. Гомумән алганда, Габделкаюм әфәндепенең пешекчелек китабы тәмле һәм файдалы ризык әзерләү турындагы мәгълүмат бирү белән генә чикләнми. Аның сәхифәләрендә татарларның башка халыкларның милли хәзинәләрендәге уңай һәм яхшы күренешләрне милли табигатенә туры китереп үзләштерә алулары кебек культурологик үзенчәлекләр дә чагылыш тапкан. Моннан тыш, бу китаптан без XIX-XX гасырлар киселешендә татарлардагы азык-төлекнең төрлелеге турында бай хәбәрләр табабыз, халыкның нинди ризыклар белән сатыш-алыш иткәнен күрәбез, хәтта ки ул замандагы сәүдә торышы турында һәм базарларда сатуда булган азык-төлекнең нинди булуы белән таныша алабыз. Мәсәлән, китаптагы рецептлардан әлеге көндә дә безнең өчен экзотик булган ризыклар хакында да белә алабыз: инжир, өрек, лимон, дәфнә яфрагы, зәһәр борыч, ногыт борчагы, баклажан, зәгъфеан, хөрмә, бәдам чикләвеге, йөзем, шпинат һәм башкалар. Моннан тыш, китапта ит ризыклары белән бергә балыктан ясалган тәгамнәр һәм яшелчә ризыклары да шактый киң тасвирланган. Йомгаклап әйткәндә, биредәге ризыклар туклыклылык белән генә түгел, ә бәлки витаминнарга һәм кыйммәтле микроматдәләргә бай булулары белән дә аерылып тора. Бу үзенчәлек әлеге китап белән танышкан һәркемнең (гәрчә ул махсус әзерлекле белгеч булмаса да) игътибарыннан читтә кала алмас. Әлеге китап үрнәгендә Габделкаюм Насыйри мирасын өйрәнү юлында тагын бер әһәмиятле, аның халык тормышын өйрәнүгә багышланган фидакарь эшчәнлегенең матур ягы ачылды, кайчандыр гарәп графикасында басылып, заманалар үзгәрү нәтиҗәсендә югалып калган бу файдалы хезмәт яңадан киң җәмәгатьчелеккә кайтарылды дип әйтергә кирәк.

**Раушания ШӘФИГУЛЛИНА,**
**филология фәннәре кандидаты,**
**Каюм Насыйри музее җитәкчесе**
**(«Татарханә» проектының презентация**
**материаллары җыентыгы**
**ТАТАРХАНӘ / ТАТАРХАНЕ / TATARHANE Казан 2022)**

# КАБАК БОТКАСЫ



*Күз төсләргә бай, матурлык чоры гына түгел, муллык вакыты да. Бакчаларда нинди генә уңыш юк: бәрәңгесе, суганы, кишере, чөгендере дисеңме, кызыл-яшел алмалары, гәрәбәдәй сары кабаклары җирдә тәгәрәшеп ята. Шул кабактан күпме ризык әзерләп була – бәлешен, бөккәнен, согын, боткасын...*

**КИРӘКЛЕ ИНГРЕДИЕНТЛАР:**

*300-400 грамм кабак;*
*150-200 грамм тары ярмасы;*
*100 грамм атланмай;*
*250 миллилитр сөт;*
*3 аш кашыгы үсемлек мае;*
*Тәменчә шикәр, тоз.*



1 *Өлгергән кабакның эчен алабыз, кабыгын арчыйбыз.*



2 *Кисәкләргә бүлеп куелган кабакны вак итеп турыйбыз.*



3 *Туралган кабакны савытка салабыз, өстенә әле генә кайнап чыккан су агызып, пешереп алабыз.*



4 *Шул арада тары ярмасын яхшылап юып, әче тәмен бетерү өчен, кайнар су салып, 2 минут пешереп алабыз һәм суын түгәбез.*



5 *Пешкән кабакны кашык белән изеп, өстенә кайнаган сөт, 3 кашык май, пешекләнгән тары ярмасы, тәменчә тоз, шикәр салып, сүрән утта болгатып пешерәбез.*




6 *Пешеп чыккач, тәлинкәләргә бүлеп, өстенә эретелгән атланмай салып чыгарабыз.*

*Ашларыгыз тәмле булсын!*

Фоторәсемнәр Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге архивыннан

# Бергәләп бизибез!



# Истәлекле даталар
2024

## ОКТЯБРЬ

**1 октябрь**

Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы Дания Фатих кызы Заһидуллинага 60 яшь (1964)

**5 октябрь**

Композитор, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Илфат Мәҗит улы Дәүләтшинга 60 яшь (1964)

**12 октябрь**

Режиссёр, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре Гыйлемхан Һади улы Мөбәрәкшинга 70 яшь (1954)

**19 октябрь**

Сынчы, Татарстан АССРның халык, РСФСРның атказанган рәссамы, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Васил Малик улы Маликовның тууына 100 ел (1924-1992)

**24 октябрь**

Рәссам Дамир Сирин улы Хафизовка 50 яшь (1974)

**26 октябрь**

Актриса, Татарстан АССРның атказанган артисты Рауза Дәүләт кызы Әхмәрованың тууына 100 ел (1924-2012)

**27 октябрь**

Рәссам, Казакъстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык рәссамы, Шаньтоу (Кытай) университетының шәрәфле профессоры, Казакъстан Республикасы Сәнгать академиясе академигы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Камил Вәлиәхмәт улы Муллашевка 80 яшь (1944)

**31 октябрь**

Скрипач, педагог, профессор, сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты, Россия Федерациясенең атказанган артисты, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Шамил Хәмит улы Монасыйповка 80 яшь (1944)

## НОЯБРЬ

2 ноябрь

Скрипкачы, дирижёр, композитор, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Республикасының халык артисты Фоат Хәмит улы Әбүбәкеревкә 80 яшь (1944)

**5 ноябрь**

Дирижёр, Татарстан АССРның халык, Россия Федерациясенең атказанган артисты, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының баш дирижёры Ренат Салават улы Салаватовка 75 яшь (1949)

**7 ноябрь**

Режиссёр, педагог, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе, СССРның халык артисты, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның Г. Тукай исемендәге, РСФСРның К.С. Станиславский исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Марсель Хәким улы Сәлимҗановның тууына 90 ел (1934-2002)

**10 ноябрь**

Музыка-театр эшлеклесе, М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры директоры, Россия Федерациясенең атказанган мәдәният хезмәткәре Рәүфәл Сабир улы Мөхәммәтҗановка 75 яшь (1949)

**12 ноябрь**

Актриса, Татарстан Республикасының атказанган артисты Гөлназ Әлбәк кызы Фәхрәзиевага 60 яшь (1964)

**13 ноябрь**

Гамәли бизәлеш сәнгате рәссамы Рәшит Гыйният улы Төхфәтуллинга 70 яшь (1954)

**18 ноябрь**

Режиссёр, педагог, Татарстан Репубикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, Россия Федерациясенең атказанган артисты Рәшит Муллагали улы Заһидуллинга 60 яшь (1964)

**20 ноябрь**

Рәссам, Россия сәнгать академиясенең заманча сәнгать өлкәсендә И.Е. Репин исемендәге премиясе лауреаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе Илгизәр Майбер улы Самакаевка 70 яшь (1954)

## ДЕКАБРЬ

**13 декабрь**

Рәссам Азат Мөхәммәт улы Байбековның тууына 100 ел (1924-2011)

**19 декабрь**

Концерт гармуннарында уйнау остасы, Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе һәм халык артисты, Бөтенсоюз гармунчылар ярышы лауреаты Фәйзулла Кәбир улы Туишевның тууына 140 ел (1884-1958)

**20 декабрь**

И.В. Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте (училищесы) оештырылуга 120 ел (1904)

**29 декабрь**

Татарстанның халык язучысы, Татарстанның, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нәкый Сираҗетдин улы Исәнбәтнең (Закировның) тууына 125 ел (1899-1992)

**https://kitaphane.tatarstan.ru сайтыннан алынды**





**Кадерле укучыларыбыз!**
2024 елның беренче яртыеллыгы өчен «Түгәрәк уен» альманахына республикабызның барлык элемтә бүлекләрендә, яисә «Почта России» сайты аша (https://podpiska.pochta.ru Индекс ПА 183 яисә «Тугарак уен» дип җыярга) онлайн да язылырга мөмкин.